КҮПФУНКЦИЯЛЕ НӘТИҖӘ

Күрсәтелгән хезмәтләр саны бер миллионга кимегән

> 3

ЧИГЕ БАРМЫ?

Бер ел эчендә беренче стадиядә яман шеш табылу очрагы 1 меңгә арткан

> 4

ИССЕЗ КУРКЫНЫЧ

Татарстанда сөрем газыннан 103 кеше зыян күргән, шуның 53е – балалар

> 5

ТЕАТР АТАСЫ

Галиәсгар Камалны җитәрлек дәрәҗәдә белмибез икән әле

>6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 16 (29176) | Сишәмбе | 6 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҮЗЕБЕЗНЕҢ БАТЫРЛАР

Илдар Мөхәммәтҗанов

Газетабыз бәйгесе

Беренче җиңү – иң кадерлесе. Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган бәйгедә өч егет тәүге мәртәбә батыр калды. Ә тагын сигезе узган елгы уңышын кабатлады. Теләчедән Раил Нургалиевка исә, Айрат Гыйлаев янәшәсенә басу өчен, нибары бер адым ясыйсы калды. Әлеге турнирда келәмнән читтә дә батырлык кирәклеген искә төшердек.

Турнир язмышы – көрәшчеләр ныклыгында

Раил димәктән, Муса Җәлил турнирының ачылыш тантанасын да Теләче батыры башлап җибәрде. Аның кечкенә улы белән батырлык турында сөйләшүе егетлекнең гаиләдә башлануын күрсәтте. «Әти, минем дә үскәч көрәшче буласым килә!» – дигән кечкенә малай соңыннан турнир вакытында да келәм яныннан китмәде диярлек. Берничә елдан келәмдә Бәхтияр Нургалиевның бил алышканын күрсәк, гаҗәп булмас.

– Илебезнең бөтенлеген саклау өчен көрәшүче ир-егетләребезнең язмышын каһарман-шагыйрь Муса Җәлил язмышына бәйләп күрсәткән ачылыш тантанасын карадык. Ул безне кабат рухландырды, тулыландырды, безнең көчле, ихтыярлы, булдыклы халык булуыбызны күрсәтте, – диде ачылыш тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың Көрәш федерациясе президиумы рәисе Марат Әхмәтов. – Әлеге дәрәҗәле турнир белән без татар көрәшенең яңа сезонын башлап җибәрәбез. Быел без аның алтмыш беренче сәхифәсен язабыз, ә турнирның дәрәҗәсе елдан-ел арта гына!

Турнир ел саен үзе дә көрәшче булган Муса Җәлил батырлыгы рухында үтә. Быел да аның шигырьләре янә бер кат күңел аша узды, хәзерге батырлар исеменнән аңа атап язылган хат егетлекнең еллар узса да җуелмас төшенчә булуын раслады. Хәзерге көндә батырлыкларын махсус хәрби операциядә күрсәтүче көрәшче ир-егетләребез безнең сәламне кабул итәр, ә бүген мәйдан тотучылар егетлекнең нәрсә икәненә тагын бер кат төшенер дип ышанабыз. Ватан сакларга киткән егетләрнең рәсемнәре зур экранга чыккач, хәтта көрәшчеләрнең дә күзләре яшьләнде.

Газетабызның баш мөхәррире Гөлнара Сабирова сүзләре белән әйтсәк, турнир язмышы – менә шушы көрәшчеләр ныклыгында.

– 61 ел элек, әлеге бәйгене гамәлгә куйганда, редакция хезмәткәрләре аның бүгенгә кадәр килеп җитәчәге турында уйлап та карамагандыр, бәлки. Әмма турнир язмышы – көрәшчеләр ныклыгында. Аны бүгенгә кадәр алып килеп җиткергән өчен, буыннан-буынга тапшырган өчен, аңа үзгә мөнәсәбәтегез өчен рәхмәт сезгә, хөрмәтле көрәшчеләр! – диде ул.

Артыгы булмый

Хәзерге вакытта Татарстанда 11770 кеше көрәш белән шөгыльләнә. Шуның 3500гә якыны – балалар һәм үсмерләр. Саннарны төрлечә бәяләп була. Моннан 15–20 еллар элек булган күрсәткечләр белән чагыштырсак, кимегәнне күрәбез. Ә бүгенге вазгыятьне исәпкә алсак, булганына шөкер итәрлек. Авыл җирендә кулына сөлге алырлык малайлар санының ничек үзгәргәнен күреп торабыз. Җитмәсә, республикада 140лап спорт төре бар. Бәйгенең беренче көнендә Татарстан Көрәш федерациясенең президиум утырышында катнашучылар булганны саклап калу, кул астындагы мөмкинлекләрдән файдалану турында сөйләштеләр.

Көрәш булмаган төбәк юк. Әмма хәлләр төрлечә. Балтач кебек, барлык бәйгеләрдә үз егетләре белән чыгыш ясаган районнар янында, зур турнирга команда туплап җибәрә алмаганнары да җитәрлек. Федерациянең президиум рәисе Марат Әхмәтов белдергәнчә, күп нәрсә районнардагы җитәкчелекнең көрәшкә мөнәсәбәтеннән тора.

Ахыры 8 нче биттә >

Кәрзин авырая

Узган елның IV кварталында Татарстанда минималь куллану кәрзинен 22493 сум күләмендә раслау күздә тотылган. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Министрлар Кабинетына бу җәһәттән карар проекты әзерләгән.

Документ кабул ителгән очракта, республикада минималь куллану кәрзине III кварталдагы (21937 сум) белән чагыштырганда 556 сумга артачак. Ул 2023 елның I кварталында – 21805 сум, II кварталында 22020 сум тәшкил иткән.

Исегезгә төшерәбез: минималь куллану кәрзине – кеше өчен иң кирәкле азык-төлек, башка товарлар һәм хезмәтләр бәясе. Бу күрсәткеч, аерым алганда, хезмәт хакы күләмен нигезләү, минималь эш хакы күләмен билгеләү, халыкның тормыш сыйфатын бәяләү өчен кулланыла.

Егерме ФАП төзеләчәк

Быел Татарстанда яңа фельдшер-акушерлык пунктлары төзү каралган. Дәүләт сатып алулары порталы мәгълүматларына караганда, республиканың берничә районында барлыгы 20 ФАП барлыкка киләчәк. Бу максатка 185 миллион сумнан артык акча юллана.

Яңа ФАПлар, аерым алганда, Әлки районы Югары Колчура, Биектау районы Өбрә һәм Бикнарат, Зәй районы Кәрәкәс авылларында, Лениногорск районы Мичурино бистәсендә, Питрәч районы Кибәк Иле, Теләче районы Балыклы, Әгерҗе районы Кырынды, Апас районы Әлмәндәр, Яшел Үзән районы Бишнә, Кукмара районы Әсән-Елга авылларында төзеләчәк.

Тагын буран

Татарстанда янә һава торышы бозыла. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, атна башында юеш кар, буран (500 метрга кадәр берни күренмәскә мөмкин) көтелә. Юлларда – бозлавык һәм кар көртләре. Һава температурасы көндез –1...–13, төнлә –16...–21 градус чикләрендә тирбәләчәк. Пәнҗешәмбе – 8 февральдән шимбәгә – 10 февральгә кадәр көндез термометрның терекөмеш баганасы –13...–16 градус күрсәтәчәк. Төнге сәгатьләрдә –13...–18.

Исегезгә төшерәбез: Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шәһәрләрдә карның начар җыештырылуын әйтеп, килеп туган проблеманы кичекмәстән хәл итәргә һәм кар яуганда авылларда яшәүчеләргә уңайлы шартлар тудырырга кушты.

Фитыр күләме билгеле

10 мартта, кояш баеганнан соң, рамазан шәриф аена керәбез. Шул сәбәпле Татарстан Диния нәзарәтендә фитыр сәдакасы, фидия һәм нисаб күләме билгеләнгән.

Нәзарәтнең матбугат хезмәте хәбәренә караганда, фитыр сәдакасын түләү өчен нисаб күләме – 43000 сум (көмеш буенча), зәкят чыгару өчен нисаб күләме – 495000 сум (алтын буенча). Фитыр сәдакасы арпа буенча исәпләгәндә – 150 сум, йөзем белән исәпләгәндә – 1000 сум. Моннан тыш сәламәтлеккә бәйле рәвештә ураза тоту мөмкинлегенә ия булмаучыларга һәр көн өчен 400 сум күләмендә фидия билгеләнгән.

Рамазан уразасы 11 мартта башлана. Соңгы көне – 9 апрель.

Матбугат хәле

Хайп түгел, хак кирәк!

Язган һәм әйткән өчен җаваплылык тоярга, бөртекне кибәктән аерырга, халык ышанычын яуларга. «Татмедиа» агентлыгының йомгаклау коллегиясендә журналистларга әнә шундый бурычлар йөкләнде. Хәер, бу бурычларның тармак вәкилләре өстеннән төшкәне дә юк инде. Заманасы нинди бит: мәгълүмат кырында да сугыш бара! Республиканың матбугат мәйданы ни хәлдә соң?

«Татар-информ»

Елына күрә каләме

«Татмедиа» агентлыгы башлыгы Айдар Сәлимгәрәев узган елның төп нәтиҗәләренә тукталды.

Иң сөендергәне шул: халыкны мизгеллек танылу алып килә торган хайптан фикерле журналистикага кире кайтара алганбыз. Кешегә хәзер төпле, тикшерелгән, меңкат иләк аша узган дөрес мәгълүмат мөһимрәк, димәк. Һәм сүз дәүләт карамагында булган мәгълүмат чаралары турында гына бармый. Айдар Сәлимгәрәев искәрткәнчә, бәйсезләре дә ил мәнфәгатьләре өчен эшли.

Йөрәкне көйдергәне дә әйтелде: 2023 елда язылу күрсәткече 15 процентка кимегән. Җитәкче моны «Россия почтасы»ның уйланылмаган сәясәтенә сылтады. Югалтулар моннан да күбрәк була алган икән. Сан теле белән әйтсәк, югалту 646973 экземплярны тәшкил итә.

2023 елның нинди рухта узганын барыбыз да аңлыйдыр инде. Журналистларга да, журналистикага да үзгәреш юлына басарга туры килде. Айдар Сәлимгәрәев сүзләре белән әйтсәк, үстек, олыгайдык.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

Табиблар кытлыгы – безнең дә авырткан җиребез. Табиблар белән тәэмин ителеш – 83, урта медицина персоналы белән тәэмин ителеш 84 процентны тәшкил итә. Начар күрсәткеч түгел. Ә менә кайбер белгечләр белән тәэмин ителеш төрле клиникаларда төрлечә. Бу проблеманы хәл итү өчен барлык мөмкинлекләрне эзләргә кирәк.

(«Эшлекле дүшәмбе»дә әйткән сүзләре)

РОССИЯДӘ – АГРОТАРМАК

2023 ЕЛГЫ НӘТИҖӘЛӘР

147 млн тонна >> бөртекле культуралар

15 мең берәмлек техника >> ташламалы лизинг буенча алынган

1 гектарга >> **65 кг** ашлама

2024 ЕЛДА

84,5 млн га >> чәчүлек җире

1 гектарга 68 кг >> ашлама кертү

** Бөтенроссия агрономнары киңәшмәсеннән*

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ФЕТНӘЧЕЛӘР ПРОФСОЮЗГА БУЙСЫНМЫЙ

Үткән атнада Якын Көнчыгышта киеренкелек артты. Аек акыл белән фикер йөрткәндә, чит ил гаскәрләрен чыгарып, күпне күргән бу җирләрне тынычлыкта калдыру яхшырак булыр иде. Әмма Көнбатышның үзендә социаль киеренкелек арта һәм сугыш карчыгалары Кызыл диңгез һәм Фарсы култыгы тирәсендәге каршылыкны уен тузы буларак файдалану ниятеннән кире кайтмаячак. Бу елларда хәл аеруча кискенләште. Йәмәнлеләр, янкиларның һава һөҗүмнәре туктамаса, Кызыл диңгез аша сузылган интернет кабельләрен өзү белән янап, ультиматум куйды. Кабельләр өзелсә, алай дөньякүләм үк катастрофа булмаячак икән ул үзе, әмма масштаблы проблемалар калкып чыгачак. Йәмәннең бригада генералы Абдул Гани Әл-Зөбәйди: «Якындагы көннәрдә Кызыл диңгездә тиңсез вакыйгалар булачак һәм Америка сугышны оттырачак», – дип белдерде. Бу янауның ни дәрәҗәдә чынлыкка туры килүен киләчәктә белербез.

Көнбатышның үз хәле хәл. Авыл кешеләре, тракторлар белән килеп, шәһәрләрне яулый. Көрәшкә көннән-көн яңа көчләр кушыла һәм географиясе дә киңәя. Төп кораллары – сыекландырылган тирес. Тиресне Көнбатыш сәясәтчеләре куркыныч ашлама рәтенә кerттеләр бит. Хәзер хөкүмәт оешмалары, полиция машиналары шуңа коена. Фермерларның хәлен аңлап була: өченче ел рәттән инде планетада авыл хуҗалыгы продуктларына бәя рекордлы дәрәҗәдә түбән төшә. Ниндидер кара көч фермерларны сыйныф буларак юк итүгә һәм халыкны ачлык кризисына әзерли. Чынлыкта фермерлар яшәү – үлем көрәше алып бара. Европа шәһәрләреннән кибет киштәләренең бушаганын сурәтләгән видеохәбәрләр ява. Ковид кризисы вакытында да хәл алай ук кискенләшмәгән иде. Голланд фермерлары Aldi супермаркетын сыекландырган нәҗескә коендырды. Француз фермерлары кибет киштәләреннән Испаниядән китерелгән яшелчәне алып ыргыта һәм: «Үзебездә дә җитештерелә торган бу продуктларны күрү никадәр аяныч», – дип кычкыралар. Француз хөкүмәте, ниһаять, көрәшнең сугыш хәленә якынаюын аңлап, фермерларның барлык таләпләрен дә үтәргә вәгъдә бирде. Аграр профсоюзлар фермерларны протестны туктатырга чакырды. Ләкин ярсыган фермерлар туктарга уйламый. Социаль челтәрләрдә профсоюз җитәкчеләренең хезмәт хакы ведомостьлары таратыла. Җитәкчеләрнең берсе дә фермерлар взносыннан түләнгән акчадан айга 9 мең евродан да кимрәк хезмәт хакы алмый икән. Ач хәлен тук белми дип, французлар көрәшне дәвам итәргә булды. Аларга ияреп, португал фермерлар да үз профсоюзларына буйсынудан баш тартты.

Россиядә

САЙЛАУ ИНФЛЯЦИЯНЕ АВЫЗЛЫКЛАРМЫ?

Көнбатыш матбугатында, санкцияләр Россия икътисадын җимермәде, дигән язмалар күренгәли. Хаклык зур аларда, әмма Россиядә дә икътисадый хәл сокланырлык ук түгел. Бәяләр үсә һәм үсәчәк. Без аларның үсешен Росстат мәгълүматларыннан түгел, ә кибет чекларыннан беләбез. Чекта язылган саннар үсә, ә күтәреп кайта торган сумкалар җиңеләя. Әйтик, йомырка бәясе төшә дип, күпме генә шатлансак та, түбәнәю – миллиметрлап, күтәрелү исә метрлап булган иде. Әмма алда март сайлавы тора. Сайлау алдыннан традицион рәвештә бәяләрне тотрыкландырырга тырышалар. 2012 һәм 2018 елгы сайлауларда шулай булган. Сайлаудан соң исә бәяләр янә ярышка чыга. Бу авторның фикере генә түгел, Үзәк банк белгечләре шулай ди. «Телеграм»да «Твердые цифры» дигән канал бар. Үзәк банкның рәсми каналы ул, анда рәсми саннар гына урын ала. Менә шул канал раслый да инде бәяләргә бәйле сайлау алды – сайлау арты вазгыятен.

Үткән атнада сайлау дип тормады, сум яңадан ябыкты, доллар калынайды. Валюта курсы – бәяләрнең төп индикаторларыннан берсе ул. Безне, доллар сайлаудан соң да артык зур сикереш ясамас, дип тынычландыралар тынычландыруын. Үткән көздә әйбәт үк сикерде бит инде ул, хәзер ял итсә дә гаҗәп түгел. Ләкин Россиянең банк системасы «валюта ачлыгы»на таба хәрәкәт итә, ди Үзәк банк статистикасы. 2023 елда клиентлар хисабындагы валюта запасы 16 процентка кимегән. Бу 2010 елдан соңгы минимум икән.

Тотрыклылык вәгъдә итә торган хәбәрләр дә бар. Аларны шатлыклы дип әйтеп булмый, хәсрәтләнерлек тә түгел. Үткән ел компанияләр хезмәткәрләрне зур хезмәт хакы белән кызыктырып аулаган иде, быел моны эшләргә хәлләреннән килми. Зур хезмәт хакына эшләгән менеджерлар көтүләре белән урамга куылырга ихтимал дип фаразлаучылар җитәрлек. Кул белән тотып эшләүче персоналны саклау хисабына «ак яка»ларны кыскартырга туры килер, диләр. Хезмәт хакларының үсеш потенциалы тукталу инфляцияне дә йөгәнләр, бәлки. Өзеп үк әйтеп булмый, әмма хезмәт хаклары кимеп, бәяләр үсеше дәвам итсә, зур проблемалар туачак. Монополиягә каршы федераль хезмәт бәяләрне тыю юлы белән туктатырга чакыра. Аны эшләсәң, тыелгысыз дефицит пәйда булачак ләкин.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов Татарстан кулланучылар берлегенең Казандагы токмач фабрикасы эшчәнлеге белән танышты. Ул күптән түгел, февральдә генә эшли башлады әле. Фабрикада көн саен 5 тоннага кадәр төрле төрдәге токмач җитештерәчәкләр. Бирeдә әзерләнгән беренче партияне инде хәрби операциядәге егетләргә озатканнар.
Рөстәм Миңнеханов предприятиенең технологик линияләрен карады, җитештерелә торган продукция белән танышты.
Яңа оешма Татпотребсоюз кибетләрен токмач белән тулысынча тәэмин итәчәк. Ел саен райпо, кооперативлар һәм кибетләр якынча 800 тонна продукция алырга ниятли. Тагын 700 тоннасы республиканың башка кибетләр челтәренә китәчәк.

АВЫЛ ДА ШӘҺӘРЧӘ ЯШӘРГӘ ТЕЛИ

Продукция әзерләүгә һәм чимал эшкәртүгә игътибарны арттырырга кирәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Татарстан кулланучылар берлегенең еллык коллегиясендә әнә шуңа басым ясады.

Татпотребсоюз рәисе Рашат Шәймәрданов сүзләренчә, кулланучылар җәмгыяте һәм кооперативлар соңгы өч елда 61,3 млрд сум акча эшләгән. 54 проценты – әзерләүгә, 26сы – сатуга, 14е – җитештерүгә, 5 проценты җәмәгать туклануына туры килә.

Татарстанның барлык районнарында да авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чималны әзерләүче, эшкәртүче, сатучы һәм җәмәгать туклануы белән шөгыльләнүче кулланучылар җәмгыяте бар. Ләкин, Татарстан Рәисе әйтүенчә, сигез районда бу эшләр бик үк яхшы оештырылмаган.

– Кем нәрсә генә әйтсә дә, авылда кулланучылар кооперациясен алыштыру юк. Өлешчә хәл итү – бизнесны оештыру гына. Кооперация авыл территорияләрен үстерүдә мөһим роль уйный. Бүген авылда 934 мең кеше яши. Һәм алар шәһәрдәге кебек үк шартларда яшәргә тели, – диде Татарстан Рәисе.

Аның сүзләренчә, Татарстанда ерак урнашкан һәм аз кеше яши торган 1,2 мең авыл бар. Һәм Татпотребсоюз аларны товар белән тәэмин итә. Күчмә сәүдә өчен ел саен автокибетләр сатып алалар, хәзерге вакытта аларның саны 135кә җиткән.

– Алар нәтиҗәле файдаланылырга тиеш. Билгеләнгән урынга бару гына җитми, халыкка сыйфатлы хезмәт күрсәтү дә мөһим, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Моннан тыш, Татарстан Рәисе сүзләренчә, стационар сәүдә объектлары да эшли. Әйтик, соңгы өч елда 39 блоклы-модульле кибетләр төзелгән, быел тагын тугыз объект сафка басачак.

– Алар эшләргә тиеш. Барлык кибетләр дә аена ким дигәндә 500 мең сум акча эшләргә тиеш. Ләкин моның өчен продукция төрлелеге һәм бәяләрнең тотрыклы булуын тәэмин итәргә кирәк, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, продукцияне әзерләү өчен дә мөмкинлекләр зур. Ләкин барлык районнар да моны кулланмый. Әйтик, Балтач, Биектау, Менделеевск һәм Түбән Кама районнарында продукция әзерләү буенча вазгыять начар.

– Татарстан 2 млн тонна сөт җитештерә, шушы өлкә белән генә шөгыльләнгәндә дә бик зур базар. Мин дару үләннәре, авыл хуҗалыгы продукциясе турында әйтеп тә тормыйм. Продукция әзерләү – авыл халкы өчен тагын бер өстәмә керем чыганагы. Шуңа күрә бу тема район башлыклары өчен дә актуаль булырга тиеш, – диде ул.

Моннан тыш, аның сүзләренчә, әле дә булса авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү буенча сораулар кала бирә.

– Бездә чимал күп, мөмкинлекләр зур. Узган ел 107 цехта 3 млрд сумлык товар эшкәртелгән. Бу саннарны анализларга кирәк. Авыл туризмы кебек үк җәмәгать туклануын да тырышып үстерергә кирәк, чөнки ул районнар, шәһәрләр һәм кооперацияләр өчен яхшы керем чыганагы булачак.

Үзенең чыгышы ахырында Рөстәм Миңнеханов кулланучылар кооперациясен үстерү буенча программа булдырырга тәкъдим итте. Аңа җавап итеп, Россия Кулланучылар җәмгыятьләренең үзәк союзы (Центросоюз РФ) советы рәисе Дмитрий Зубов Мәскәүдә сентябрь ахырында студентлар катнашында форум узачагын һәм анда кулланучылар кооперациясен үстерү буенча федераль программа турында хәбәр ителәчәген әйтте. Үрнәк итеп Татарстан тәҗрибәсен күрсәтергә ниятлиләр. Шулай булгач, сынатырга ярамый!

ГАДЕЛЛЕК СОРАУ

ДЕПУТАТЛАР СУБСИДИЯ БИРҮ ТӘРТИПЛӘРЕННӘН КАНӘГАТЬ ТҮГЕЛ

Авыл хуҗалыгы

Авыл хуҗалыгы оешмаларына субсидия бирү тәртибен карарга, лейкозлы терлекләре булган хуҗалыкларга игътибарны көчәйтергә кирәк. Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында әнә шул мәсьәләләр турында фикер алыштылар.

Төп доклад белән авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов чыгыш ясады. Аның сүзләренчә, узган ел дәүләт программасын тормышка ашыру өчен 18,1 млрд сум (шул исәптән 6,1 млрд сумы – федераль казнадан) акча каралган булган. Быел федераль акча 6,5 млрд сумны тәшкил итә. Тик Ленар Гарипов бу акчаның ел дәвамында уңай якка үзгәрүен әйтте. Димәк, авылга ярдәм чаралары кимеми.

– Чәчүлек мәйданнарын узган елгы кебек үк саклап калырга планлаштырабыз. Шулай ук һәр гектарга 80 килограммнан да ким булмаган ашлама кертергә ниятлибез. Моның өчен барлык мөмкинлекләр дә бар, – диде ул.

Терлекчелеккә килгәндә, узган ел аграрийлар өчен авыр булса да, 10640 башка исәпләнгән 19 сөт комплексы сафка баскан. Әлеге вакытта республикада 20 инвестпроектны тормышка ашырып киләләр, быел шуларның 11е төзелеп бетеп, терлекләрне кабул итәргә әзер булачак.

Ленар Гариповның чыгышыннан соң депутатлар авыл хуҗалыгы оешмаларына бирелә торган субсидия тәртипләре белән кызыксынды. Ул районнардагы оешмаларга өч ел эчендә 5 млрд сум күләмендә субсидия бирелми калганлыгын әйтте.

– Бу безгә аңлашылып бетми. Аграр тармактагы кагыйдәләр һәрвакыт бөтен хуҗалыкларга да – зур, вак предприятиеләргә дә бертөрле булды, – диде Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты җитәкчесе урынбасары Таһир Һадиев. – Ләкин без кече формадагы оешмаларның, акча бетү сәбәпле, субсидия ала алмавы турында ишетеп торабыз. Әйтик, 2021 елда «Союзагро» оешмасына – 14 млрд, «Марс» хуҗалыгына 2 млн сум тирәсе субсидия бирелмәгән. 2022 елда алар шулай ук ала алмаганнар. Миңа калса, сез шартларны бик хәйләкәр ысул белән төзегәнсез. Ни өчендер һаман бер оешмалар махсус рәвештә артка чигерелә. Һәрхәлдә, миндә шундый тәэсир кала.

Шуннан соң ул авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең узган өч елда 70/30 программасы буенча күпме техника алуына бәйле мәгълүматны әзерләп җиткерүләрен сорады.

– Кешеләр бит бу программага өметләнә. Өч ел узгач, бәяләр дә үзгәрә. Ул вакытта программадан файдаланган булсалар, яхшы гына техника алырга мөмкинлек булыр иде. Ә хәзер ул акча кыйммәтен югалта, – диде Таһир Һадиев.

Утырышта күтәрелгән тагын бер мәсьәлә – терлекләрдә лейкоз булды. Комитет җитәкчесе Азат Хамаев әлеге авыруга бармак аша гына караган районнарны тәнкыйтьләде. Дөрес, районнарын гына атамады.

– Бу проблема елдан-ел кимүгә таба бара, ләкин чыннан да, бик начар эшли торган районнар бар. Аларны мәҗбүриләп тә булмый. Шуңа күрә ветеринария ягыннан да таләпләр катгыйланачак. Бу беренче чиратта сөт тапшыруга кагылачак. Ветеринария озата бару документларында барлык мәгълүмат күрсәтеләчәк. Кыскасы, алга таба да без бу мәсьәләдә эшләүне дәвам итәбез, – диде аның тәнкыйтенә каршы Ленар Гарипов.

Ел башында «ВТ» хәбәрчесенең Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов белән әңгәмәсе вакытында әлеге тема шулай ук күтәрелгән иде. Ул вакытта баш ветеринар Лениногорск, Яңа Чишмә, Спас, Чирмешән, Лаеш, Кама Тамагы районнары терлекләрдәге лейкоз авыруына каршы бөтенләй шөгыльләнмәүләрен, аларда авыру терлекләр 10 проценттан артык булуын әйткән иде.

– Болар – терлекчелеккә бармак аша гына караучы районнар. Киләчәктә әлеге авыруга федераль таләпләр тагын да артачак. Авыру сыердан савып алынган сөтнең бәясе шушы 1–2 ел эчендә бөтенләй башка бәядән йөреячәк, шуңа күрә моңа әзер булып торырга кирәк. Соңгы елларда бу мәсьәләгә Тукай, Алабуга, Теләче, Зәй, Сарман, Кайбыч районнары, зур көч куеп, авырудан чистарып бетте. Балтач, Әтнә, Арча, Саба – болай да лейкоздан чиста районнар, – дигән иде Алмаз Хисаметдинов.

Моннан тыш, Азат Хамаев терлек саны кимү сәбәпләрен дә яхшылап өйрәнеп, министрлыкның анализлы мәгълүматын җиткерүен сорады.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Нәтиҗә

Үзебезгә кирәк

Әйләнә-тирә мохит турында кайгырту үзебезгә кирәк. Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама төбәкара идарәсенең киңәйтелгән киңәшмәсендә әлеге фикер кат-кат яңгырады. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Узган ел Росприроднадзорның Идел-Кама төбәкара идарәсе 1,7 мең контроль-күзәтчелек чарасы үткәргән. Планнан тыш тикшерүләр саны гына да 300дән артып киткән. Аерым алганда, былтыр капиталь төзелеш объектларындагы эшнең тиешле таләпләргә туры килүенә бәйле 284 тикшерү үткәргәннәр.

– Без «Татнефть» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ, «Казаноргсинтез» ГАҖ, Казан дары заводы, кече нефть компанияләре объектлары, шулай ук чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләүдә экологик таләпләр үтәлүне тикшереп торабыз, – дип сөйләде идарә җитәкчесе Фаяз Шакиров.

Баксаң, Росприроднадзор бәяләмәсен алып тормыйча гына сафка баскан объектлар да бар икән. «Мәсәлән, Казанда, Яшел Үзәндә һәм Йошкар-Олада ведомствога хәбәр итмичә генә чистарту корылмалары төзи башлаганнар», – диде идарә җитәкчесе. Ул муниципаль район башлыкларына рөхсәт документларын алу мәҗбүри булуын тагын бер кат искәртте.

– Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәсендә, былтыр идарә тарафыннан 647 беркетмә төзелде, 111 очрак буенча әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыян күләме 6 миллиард сумнан да артып китә, – диде Фаяз Шакиров.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, без – зур сәнәгать республикасы. Әмма халыкка яшәү өчен тиешле шартлар тудыру турында да онытырга ярамый.

– Уңайлы яшәү тирәлеге барлыкка китермәсәк, бөтен эшебез, республиканың җәлеп итүчәнлеге юкка чыгачак, – диде Татарстан Рәисе. – Әйе, без бу юнәлештә бик күп эшлибез. Әмма алда торган эшләр дә шактый. Бу – урман хуҗалыгы да, су киңлекләре дә, һава сыйфаты да. Моны кемнәрдер өчен түгел, ә үзебезгә дип эшлибез. Бу – безнең Җир, бирeдә балаларыбыз, оныкларыбыз яшәячәк.

Дәүләт Советында

Дуслыкны ныгытып

Татарстан белән Беларусь арасындагы үзара тыгыз элемтәләр – безнең зур казанышыбыз. Бу нык дуслыкны сакларга кирәк. Фәрит Мөхәммәтшин Минск шәһәрендә Беларусь Республикасының Милли Җыены республика советы Рәисе Наталья Кочанова белән очрашуда шулай дип белдерде. Дәүләт Советы Рәисе җитәкчелегендә парламент делегациясе әгъзалары Минск өлкәсендә ике көнлек рәсми сәфәрдә булып кайтты.

Очрашуда Наталья Кочанова Татарстан белән Беларусь арасында үзара җылы мөнәсәбәтләр урнашуын әйтте.

Аның әйтүенчә, хәзерге вакытта Россия белән Беларусь кайбер дәүләтара оешмаларда бергәләп эшли. «Безгә ике ил төбәкләренең законнар чыгару органнары арасындагы хезмәттәшлекне киңәйтергә кирәк, – диде Наталья Кочанова. – Безнең өчен төбәкләрнең хезмәттәшлеге бик мөһим. Татарстан делегациясенең бүгенге визиты – элегрәк ирешелгән килешүләрне гамәлгә ашыру ул».

Фәрит Мөхәммәтшин, үз чиратында: «Бер-беребездән өйрәнерлек әйберләр байтак. Күп кенә мәсьәләләр буенча тәҗрибә алышып эшләүне дәвам иттерергә кирәк», – дип билгеләп үтте. Татарстан парламенты башлыгы Наталья Кочанованы җавап визиты белән Казанга чакырды.

Россиянең Беларусь Республикасындагы илчесе Борис Грызлов белән очрашу Дәүләт Советы депутатларының Минск өлкәсенә сәфәрендә тагын бер мөһим чарага әйләнде. Анда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, депутатлар Лилия Маврина, Альберт Хәбибуллин катнашты.

Борис Грызлов әйтүенчә, Татарстан белән Беларусь төбәкләренең үзара хезмәттәшлеген үстерү башлыча Россия – Беларусь союзын ныгытуга ярдәм итә. Илче үзара сәүдә-икътисадый, мәдәни һәм парламентара элемтәләрне югары бәяләде.

«Дустанә элемтәләребез кысасында Татарстан җитәкчелеге Беларуська еш килә һәм бу визитлар һәрвакыт бик нәтиҗәле булып чыга, – дип басым ясап әйтте Борис Грызлов. – Товар әйләнешенең күләмле һәм гуманитар проектларның күп булуы шул хакта сөйли. Беларусь вәкилләре дә Казанда еш була. Татарстан парламенты делегациясенең бүгенге эшлекле сәфәре зур әһәмияткә ия, чөнки Россия белән Беларусь арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне алга таба киңәйтүгә нигез булдыра».

Фәрит Мөхәммәтшин исә, очрашып, хезмәттәшлек юнәлешләрен карау мөмкинлеге тудырылган өчен, илчегә рәхмәт белдерде.

Очрашуда быел Казанда узачак халыкара чаралар: Киләчәк уеннары, БРИКС уеннары, БРИКС дәүләтләре башлыкларының саммиты, «РОСТКИ» Россия – Кытай форумы турында да сүз барды. Беларусь вәкилләре бу чараларда актив катнашырга ниятли.

«Бүгенге очрашуда күп мәсьәләләр күтәрелде, – дип билгеләп үтте Татарстан парламенты рәисе очрашудан соң журналистлар белән әңгәмәсендә. – Бүген тугандаш Беларусь халкы белән үзара тыгыз элемтәләрне тагын да ныгытуның, барлык юнәлешләр буенча хезмәттәшлекне җайга салуның башка вакыттагыга караганда мөһимрәк булуын аңлыйбыз. Беларусь Республикасы – безнең якын дустыбыз, күршебез һәм партнерыбыз».

ХАЙП ТҮГЕЛ, ХАК КИРӘК!

tatar-inform

<Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Шунысы шатландыра: җаваплылык йөге дип, журналист үз эшенең төп максатын онытмады. Бу – җәмгыятьтәге проблемаларны вакытында күрү, аларны күрсәтү, хәл итү, – диде тармак җитәкчесе.

Айдар Сәлимгәрәев әйтүенчә, зур текстларны укучылар арткан. Монысы өчен «Телеграм» челтәренә рәхмәт. Нәрсә турында укыйлар, дисәгез, кешегә файдалы мәгълүмат кирәк, ди.

Коллегиядә каләм ияләренә кытлык турында да, хезмәт хаклары турында да сүз булмады. Телгә алмагач, бу яктан хәлләр яхшырган яисә тискәре якка үзгәреш булмаган дип өметләнә алабыздыр, шәт.

Нәрсәгә игътибарны арттырасы бар?

Мәгълүмат кырында да сугыш бара. Айдар Сәлимгәрәев сүзләренә караганда, журналистның тагын бер бурычы – ялган мәгълүматка каршы тору. Соңгы арада бөртекне кибәктән аера белү гаять мөһим шул. Фейк, коткы тарату кимер дип көтәсе юк. Айдар Сәлимгәрәев әйтүенчә, алар тагын да күбрәк булачак әле. Чөнки алда – мөһим сәяси вакыйгалар. Тармак җитәкчесе журналистларны уяу булырга чакырды.

2024 елда журналистлар күз уңында нинди темаларны тотарга тиеш соң? Айдар Сәлимгәрәев әйтүенчә, болар – Президент сайлау, Татарстан Дәүләт Советына депутатлар сайлау, махсус хәрби операция (сүз уңаеннан, бу темага былтыр 30 меңнән артык материал әзерләнгән), миграцион сәясәт, яшьләр сәясәте, «Киләчәк уеннары», «KazanForum», «РОСТКИ» форумнары, БРИКС уеннары һәм саммиты. Кыскасы, эш күп, журналистларның каләме генә тутыкмасын!

ТАТАРСТАН МАТБУГАТЫ – САННАРДА

339 басма мәгълүмат чарасы

60 телеканал һәм телепрограмма

205 электрон басма

7 мәгълүмат агентлыгы

60 радиоканал һәм радиопрограмма

3000+ хезмәткәр

ТАТАРСТАН МАТБУГАТЫНЫҢ САЙТ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРЕ

161 млн караулар **(+13,5%)**
8,4 млн язылучы **(+12%)**

Үгет-нәсыйхәт

Караш башка, эш шул ук. Коллегиядә катнашкан Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сафәров тармак вәкилләренә агымдагы елга иске яңа бурыч-максатлар куйды.

1. Журналистлар илнең мәгълүмати иминлеге өчен җаваплы. Димәк, халыкның иминлеге өчен дә. Әсгать Сафәров әйтүенчә, дошманнарның бар игътибары март аендагы Президент сайлавына юнәлгән булачак. Шуңа күрә журналистлар бу җәһәттән уяулыкны тагын да арттырырга тиеш.
2. Фейкларга, провокация тудыручыларга каршы көрәш. Көрәшен инкарь итеп каласы гына түгел, «Нигә?», «Ни өчен?» дигән сорауларга җавап биреп, аңлатырга, дөрес мәгълүмат бирергә кирәк.
3. Гаилә елы, Фәнни-технологик үсеш елына, махсус хәрби операциягә бәйле язмалар әзерләргә, ясалма интеллект, нейрочелтәр мөмкинлекләреннән файдаланырга.
4. Матбугат чаралары җилкәсендә – милләт, мирас темалары да. Татарстанда анысы да төрледән-төрле һәм бик күп бит.

СҮЗ УҢАЕННАН. «ВТ» журналисты Риман Гыйлемханов «ТАССР төзелүгә 100 ел» медаленә лаек булды. Бүләкне Әсгать Сафәров тапшырды.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Мәгълүмат чыганаклары	
Телевидение	47%
Интернет мәгълүмат басмалары	37%
Телеграм-каналлар	25%
Чат-төркемнәр	22%
Дус-иш, хезмәттәшләр белән аралашу	17%
Видео (Ютуб, Рутуб)	14%
Социаль челтәрләрдәге төркемнәр	14%
Радио	9%
Басма мәгълүмат чаралары	5%

СЫЙФАТЫНА КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Йомгак

Халыкка күрсәтелгән хезмәтләр саны бер миллионга диярлек кимегән, ә менә мөрәҗәгать итүчеләр – шул ук дәрәҗәдә. Башкалада Күпфункцияле үзәкләрнең былтыргы эшенә йомгак ясадылар.

– Узган ел үзәкләр аша барлыгы 5,1 миллион хезмәт күрсәтелде. Алдагы елны исә әлеге сан 6,05 миллионны тәшкил итте, – диде Татарстанда КФҮ директоры Ленара Мозафарова.

Ул шунда ук ачыклык та кертте: «Безгә мөрәҗәгать итүчеләр саны кимемәде. Узган ел Салым федераль хезмәте Бердәм салым счетына күчү сәбәпле, гыйнвар – август айларында без халыкка салымга бәйле бурычлары турында белешмә җибәрә алмадык. Мондый «сәлам хатлары»н кабат сентябрьдән генә юллый башладык. КФҮ тәкъдим иткән башка хезмәтләргә карата сорау һәм безгә мөрәҗәгать итүчеләр алдагы ел дәрәҗәсендә калды», – диде Ленара Мозафарова.

Җитәкче иң күп күрсәтелгән хезмәтләрне дә атады. Беренче урында – милеккә хокукны теркәү. Былтыр әлеге төр хезмәттән 1,5 миллионга якын кеше файдаланган. Россия гражданнарын регистрация теркәве – икенче урында (344 мең). Беренче өчлеккә Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) белешмә алу (319 мең) да эләккән. Татарстанда салымга бәйле бурычларны тикшерү (280 мең), Россия паспорты алу (218 мең) кебек хезмәтләргә карата да кызыксыну зур.

Хәтерләсәгез, былтыр КФҮ тирәсендә ыгы-зыгы да купты. Ленара Мозафарова узган елның августында интернетта таралган ялган хәбәрдән соң КФҮләргә озын-озак чиратка тезелгән халык белән ничек эшләүләрен сөйләде.

– Интернетта, социаль челтәрләрдә биометрик мәгълүматны тапшырудан баш тарту турындагы гаризаны 31 августка кадәр генә язарга ярый, өлгермәсәгез, сезнең турындагы мәгълүмат әллә кемнәр кулына эләгергә мөмкин, дигән эчтәлектәге ялган хәбәрләр таралды. 2022 ел азагында кабул ителгән яңа закон нигезендә, дәүләт илдә яшәүчеләрнең биометрик мәгълүматын Бердәм биометрия системасы аша гына җыя, саклый һәм эшкәртә ала. Биометрияңне теләсә кайсы вакытта бетерергә һәм үзең турында мәгълүматны эшкәртүгә рөхсәтне кире алырга мөмкин, – диде Ленара Мозафарова.

Денис Бунтуков

– Август азагында безгә күпләп мөрәҗәгать итүчеләр бирегә ни өчен килүләрен үзләре дә аңлап бетермәде хәтта. Хезмәткәрләребезнең һөнәри осталыгы гына башка төр хезмәтләр күрсәтүгә зыян китермичә, имеш-мимешләргә бәйле чиратларны җиңәргә ярдәм итте.

Былтыр Татарстанда 33921 мең кеше биометрик мәгълүматны бетерүгә бәйле гариза язган.

Районнардагы җирле хакимият органнары гына ара-тирә эшне боза икән. Киңәшмәдә КФҮ аша тәкъдим ителүче хезмәтне вакытында күрсәтмәгән муниципаль берәмлекләрне атадылар. Ленара Мозафарова сүзләренә караганда, былтыр җирле хакимият органнары тарафыннан 2115 шундый очрак теркәлгән.

– Аерым алганда, Түбән Кама районында шундый – 478, Лаешта – 387, Биектауда 351 очрак теркәлде, – диде Ленара Мозафарова.

Форсаттан файдаланып, ул 15–17 мартта узачак Россия Президентын сайлау вакытында теркәлү урыны буенча сайлау участогына бара алмаучыларга нишләргә икәнен әйтте:

> Тиздән безне бөтен ил халкы өчен мөһим вакыйга көтә. Россия Президентын сайлау узачак. Бу вакытта ялга яки эш буенча китеп, теркәлү урыны буенча сайлау участогына бара алмаучылар, гариза язып, үзләренә уңайлы булган тавыш бирү урынын сайлый ала. Моны «Мобиль сайлаучы» мобиль кушымтасы аша да, шәхсән күпфункцияле үзәккә килеп гариза язып та эшләп була.

Җитәкче сүзләренә караганда, Россия Президенты кандидатурасы өчен тавыш бирү өчен Татарстан гына түгел, илнең теләсә кайсы шәһәрендәге сайлау участогын сайларга мөмкин. «Шунысын да искәртик: моны алдан эшләргә кирәк. Күпфункцияле үзәкләрдә гаризалар 11 мартка кадәр кабул ителә. «Мобиль сайлаучы» кушымтасы Дәүләт хезмәтләре порталында да гамәлдә», – диделәр утырышта.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фән калҗасы

ГОД НАУЧНО-ТЕХНОЛОГИЧЕСКОГО РАЗВИТИЯ В ТАТАРСТАНЕ
ТАТАРСТАНДА ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ ЕЛЫ

Казан Кремлендә Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов фән һәм технология өлкәсендә казанышларга ирешкән галимнәргә дәүләт премияләре тапшырды. Алар арасында тел, геодезия, авыл хуҗалыгы, машина төзелеше тармакларына өлеш керткән галимнәр бар.

– Соңгы вакытта республика югары уку йортлары һәм фәнни тикшеренү оешмалары әһәмиятле уңышка иреште. Күптән түгел «Планетада сыек углеводородлар запасларын рациональ үзләштерү» фәнни үзәгенең Күзәтчелек советы утырышы булды. Без хезмәттәшләребез белән эшләнмәләрнең халыкара дәрәҗәдә танылуына инандык, – диде Рөстәм Миңнеханов бүләкләр тапшыру тантанасында.

Рәис әйтүенчә, Татарстанда илнең алдынгы инженерлык мәктәпләренең уннан бер өлеше урнашкан. Хәзерге вакытта республика икътисадының база тармаклары иң югары квалификацияле инженер кадрларын әзерләү өчен заманча җиһазлар белән җиһазландырылган. Татарстан югары уку йортлары «Приоритет 2030» стратегик программасы кысасында уңышка ирешкән.

Рөстәм Миңнеханов сөенечле саннар да китерде. Россия тарихында беренче тапкыр республиканың фән һәм технологияләр өлкәсендә эшләүчеләр саны 14 мең (!) кешедән артып киткән. Фәнни эзләнүләргә киткән эчке чыгымнар күләме исә рекордлы 30 млрд сумга якынлашкан. Илкүләм рейтингта төбәкләр арасында Татарстан икенче урынны алган. Рөстәм Миңнеханов әлеге казанышларда залда утырган галимнәрнең өлеше зур булуын әйтте. Аның фикеренчә, әлеге казанышлар яңалыгы һәм кыйммәте белән аерылып тора. Тикшеренүләр һәм эшләнмәләрнең үзенчәлеге – тәҗрибәле галимнәр хезмәтләренең яшьләр энергиясе, тәкъдимнәре белән даими тулыланып торуында.

«Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты» исеменә дүрт проект буенча эш төркеме җитәкчеләре һәм әгъзалары лаек булды. Алты томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» дә иң нәтиҗәлеләрнең берсе дип табылган. Әлеге проект җитәкчесе филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, вице-президенты Айнур Тимерханов белдергәнчә, бу хезмәт – татар халкының рухи мирасын саклау, барлау, киләчәк буыннарга тапшыру юнәлешендә зур казаныш. Электрон варианты исә телдә булган үзгәрешләрне җәһәт кенә теркәп кую мөмкинлеге бирә.

– Татар халкының да, башка халыклар кебек, дөньяны танып белүе, күзаллавы сүзләр хәзинәсендә чагылыш таба. Сүзлекләр күп. Ә аңлатмалы сүзлек – сүзлекләрнең атасы. Шундый сүзлегебез бар. Ул халкыбызның дөньяга карашын, күзаллавын, менталитетын чагылдыра. Шул ягы белән дә әлеге хезмәт җәмгыять өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле. Бу – чирек гасырга сузылган хезмәт. Аны башкаруда берничә буын сүзлекче галимнәр катнашты. Кайберләре бакыйлыкка күчте. Әлеге хезмәтнең башында остазыбыз Фоат Ганиев тора. Сүзлекне бастыру дәүләт программасы кысасында башкарылды, – диде ул.

Аңлатмалы сүзлеккә җанисәп, җанатар, күксөзәр, күктишәр, үзизоляцияләү кебек яңа сүзләр дә кергән. Мәдәнияткә, һөнәрчелеккә бәйле югалып барган сүзләр дә бар. Неологизм, архаизмнар, хәтта хаталы сүзләр дә теркәлгән.

Газета хәбәрчесе Айнур Тимерхановтан яңа сүзләрнең тормышка ни дәрәҗәдә кереп китү-китмәве турында да кызыксынды.

– Аңлатмалы сүзлеккә кертү принципларының берсе ул – сүзләрнең алдан публицистикада, газета-журналларда кулланылып, аннан әдәби әсәрләргә кереп киткәнлеген исәпкә алу. Ул сүзләрне рәсемнәр, әдәбият, фольклорда булган мисаллар белән дәлилләп бардык. Бу сүзлектә сүзләр саны да күбрәк. Биредә кайбер сүзләрнең мәгънәләре 3–4 тапкыр киңрәк бирелде. Әмма бу моңа кадәр телебез ярлырак булган дигән сүз түгел, – дип җавап бирде ул.

Идел буе федераль округы буенча җирләрне мелиорацияләү һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе директоры Марс Хисмәтуллин җитәкчелегендә башкарылган хезмәт тә – иң лаеклыларның берсе. Ул Татарстанда авыл хуҗалыгы җитештерүенең икътисадый нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итә торган мелиорацияле игенчелекнең инновацион алымнарын эшләү, гамәлгә кертүгә багышланган. Ми-38 вертолетын сериядә җитештерүгә кую эшенә үз өлешен кертүчеләр дә Рәис кулыннан бүләк алды. Ясалма интеллект кулланып, комплекслы мәгълүматлар җыюны һәм эшкәртүне автоматлаштырып, махсус билгеләнештәге геодезия челтәрен эшләү, төзү һәм эшләтүгә бәйле хезмәт авторлары да сәхнәгә чыкты.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе 1993 елдан бирле тапшырыла. Шушы вакыт эчендә **191** фәнни хезмәт югары премиягә, **1078** кеше «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты» исеменә лаек булган.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

О.И. Павлованы Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы итеп раслау турында

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирәм:
1. «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы рәисе киңәшчесе Павлова Ольга Ивановнаны Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы итеп расларга.
2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов
Казан, Кремль
2024 ел, 03 февраль
№ 83

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Җиңү масайта, җиңелү сабак бирә

«Японнар туп аталар, Порт-Артурны ваталар, кайсы аяксыз, кайсы кулсыз, тәгәрәшеп яталар…» Рус-япон сугышы башлануга бу атнаны 120 ел була.

Кояш чыгышы иле белән Россия соңгы бер гасыр – гасыр ярым дәвердә, ни кызганыч, бер дә тынышып, дустанә мөнәсәбәттә яши алмыйлар. Әйтергә кирәк: 1904 елның февралендә башланган ул бәрелештән тыш, Икенче Бөтендөнья сугышы чорында да әлеге ике ил бер-берсенә каршы ике лагерьда торды. Төгәлрәк әйткәндә, Япония, СССРга басып кермәсә дә, Гитлер Германиясенең аркадашы, ягъни союзнигы булды. Инде килеп менә бүген дә утраулар иле Россиягә санкцияләр керткән дәүләтләр арасында. Кая ул дуслык?! Болар гына җитмәгән, Кояш чыгышы иленең Россиягә территориаль дәгъвалары да бар – Курил тезмәсенә караган ике утрауны алар үзләренеке саный, «кайтару»ны сорый.

Япония Премьер-министры әле берничә көн элек кенә янә дә бер кат Россия белән Тынычлык килешүе төзү кирәклеге хакында белдерде. Кемдер: «Нинди тынычлык килешүе тагын, без бит алар белән сугыш хәлендә түгел», – дияр. Анысы шулай. Тик Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамлануга 78 ел узып та, шушы көнгә кадәр, ике дәүләтнең үзара тыныч яшәвен раслаган документка кул куелганы юк әле. Бу хәл дә – ике арага, мөнәсәбәтләргә чөй кагып торган факторларның берсе. Тынычлык килешүе булмауның сәбәбе, зурдан алганда, тагын да шул гаугалы ике утрауга барып тоташа. Шунысын да әйтик: 1945 елга кадәр Сахалин утравының яртысы, Курил утраулары тулысы белән Япониягә караган. Сахалинга бүген алар ымсынмый, чөнки без язган 1904–1905 елгы сугышка тикле ул тулысы белән Россия империясенеке була.

Моннан нәкъ 120 ел элек башланган Рус-япон сугышына кайтыйк. Яулый-яулый, яңа территорияләрне үзенә куша-куша, Тын океанга кадәр барып җиткән рус патшаларына моңарчы булган биләмәләр генә аз тоелган, күрәсең. Аларның, киңәя-киңәя, Кытайның төньяк-көнчыгыш өлеше булган Маньчжурияне, Корея ярымутравын да кулга төшерәсе, Сары диңгезгә дә хуҗа буласы килә. Империя статусында булган Кояш чыгышы иленең дә нәфесе зурдан – алда саналган җирләр япон утрауларына якынлык сәбәпле, аларны ул кавем үзенеке, ким дигәндә үз мәнфәгатьләре зонасы итеп күрә. Кыскасы, ике империя, биләмәләрне тыныч юл белән бүлешә алмыйча, коралллы канкоешка кереп китә.

Россия дигәндә, сугышка керүнең башка максаты булуын да билгеләү дөрес булыр. Ил өстендә инкыйлаб шәүләсе йөри – бусагада, менә-менә кабынып китәм дип, революция – Беренче рус инкыйлабы тора. Аны булдырмый калу, монархияне ныгыту, илдә патриотик кәефләрне арттыру өчен өлкән туган телендә «Маленькая победоносная война» дип аталган сугыш бик тә кирәк була. Кире нәтиҗәгә киленер – ил сугышта җиңелер, революцияне тизләтер, дигән уй күпләрнең башына да килми. Идарәче даирәләрдә, алагаем Россия кечкенә Японияне бик тиз акылга утыртачак, дигән уйлар өстенлек итә. Тик…

Ел ярым чамасы барган сугышта Россия җиңелә. Диңгездә генә түгел, коры җирдә дә. «Җиңү китерәчәк кечкенә сугыш» җиңү китермәү генә җитмәгән, шактый масштаблы була, олы югалтуларга илтә. Корея ярымутравы белән Япония арасына урнашкан Цусима атавы янындагы хәлиткеч бәрелештән соң Тын океан флоты гомумән дә яшәүдән туктый. Дистәдән артык хәрби кораб японнар кулына төшә яисә юк ителә.

Әлбәттә, Россия сугыштан сабаклар ала. Еракта, җир читендә сугыш алып баруның кыенлыкларын гына түгел, армия белән флоттагы бар булган җитешсезлекләрне дә ачып сала ул вакыйга. Армияне, флотны, эш узгач, соңга калып булса да, хәзергечә әйткәндә, модернизацияләргә, яңадан корырга керешәләр. Патша хәзрәтләре дә, бәлки, биләмәләрне артыгын киңәйтү, күперүнең яхшыга илтмәвенә, сугышның да син теләгән сценарий буенча китмичә, гел башка нәтиҗәләргә илтүенә төшенгәндер. Ләкин, патшалар дигәндә, биредә барыбер «Тарихның төп сабагы – аннан бер сабак та алынмау» дигән тәгъбирне кабатлау бик тә урынлы…

Японнарга килгәндә, «Алар яулаган җиңү аларга күпмедер күләмдә «аю хезмәте» күрсәтмәде микән?» – дип сорыйсы да килә. Ни өчен дигәндә, җиңү, бигрәк тә чагыштырмача җиңел килгән җиңү башны әйләндерми, яңа «батырлык»ларга рухландырмый калмый. Кояш чыгышы илендәге аннан соң чәчәк аткан милитаризм һәм империализм, Азия – Тын океан зонасының хәтсез илләрен яулап, Икенче Бөтендөнья сугышының үзәгендә кайнау шуны дәлилли кебек. Ә менә соңгы ул сугышта җиңелү япон халкына уңай сабак бирде, дию дә бик дөрес булыр.

Япон милитаризмы тар-мар ителгәч, көнчыгыш күршебез, әлбәттә, АКШ ярдәме белән, үз халык хуҗалыгын шактый тиз арада торгыза, заманча итә алды. Торгызып кына калмады, Кытай күтәрелгәнче, ике-өч дистә ел буе дөньяның икенче икътисады ролендә дә йөрде. Бу күренешне «япон феномены» дип атадылар. Бүген алар почетлы өченче урында. Бу хәл Японияненң үтә дә хәлле, алдынгы дәүләт икәнлеген раслый. Алар җитештергән автомобильләрне, электрониканы, алар төзегән судноларны бөтен дөньяда беләләр… «Күршең үзеңнән яхшы булсын» дигән татар әйтеме һәр ике якка да карый – алар белән дус-тату яшәгәндә дә бик ярар иде. Тик әлегә, күрүебезчә, барып чыкмый.

Җиңелү айныта, дидек. Берәр хикмәт белән Кояш чыгышы иле үз вакытында – 1904 елда шәпләп «кыйналган» булса, ихтимал, соңрак Италия белән Германиягә аркадашлык та, күбебез белгән Перл-Харбор да, алар биргән 2,5 млн корбан, Хиросима белән Нагасаки да булмас иде. Тик, ни кызганыч, барысы да булды…

БАЛАЛЫ НИГЕЗ

Торак базары

Кечкенә бала тәрбияләүче гаиләләргә сөенче! Илдә «Гаилә ипотекасы» программасын озайтырга җыеналар. Бу хакта Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин әйтте. Билгеле булганча, 6 процентлы әлеге программа бу елның 1 июленә кадәр гамәлдә. Яңалык чынга ашса, алга таба торак бәясе дә төшә башларга мөмкин, ди белгечләр. Түбә турындагы хыял чынга ашарлыкмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанда яшәүче Рамилә һәм Алмаз Гарифуллиннар «Гаилә ипотекасы»ннан файдаланган инде. 2019 елда икенче балалары тугач, улларына дип, әлеге программа ярдәмендә бер бүлмәле фатир сатып алганнар.

– Банк 6 процентлы ипотекага үзеннән дә ташлама өстәп, акчаны бурычка 5,4 процент белән бирде. Бүген уртача кредит ставкасы 18–20 процент икәнен искә алсак, бу – бик аз. 2019 елда 2,8 миллион сумга сатып алган 32 квадрат метрлы фатир өчен аена 15 мең сум чамасы акча түлибез. Кечкенә бала тәрбияләүче гаиләләрнең чыгымнары болай да бик күп. Кредит исә гаиләбезгә артык авырлык китерми, – ди гаилә башлыгы.

Ил күләмендә берничә ташламалы ипотека программасы гамәлдә: яңа йортлардагы фатирларга «Ташламалы ипотека» – 8%, «Гаилә ипотекасы» – 6%, IT белгечләргә ипотека – 5%, «Авыл ипотекасы» – 3%, «Ерак Көнчыгыш ипотекасы» – 2%, Россиянең яңа төбәкләрендә яшәүчеләр өчен ташламалы ипотека 2% тәшкил итә. Моннан тыш, илнең кайбер төбәкләрендә яшәү шартларын яхшыртуга бәйле аерым программалар да бар. «Ташламалы ипотека» һәм «Гаилә ипотекасы» рәсми рәвештә 2024 елның 1 июленә кадәр гамәлдә.

4 февраль көнне Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин «Гаилә ипотекасы» программасының озайтылачагын әйтте. Хәтерләсәгез, узган ел азагында әлеге мәсьәләне Россия Президенты Владимир Путин да күтәргән иде. Мәскәүдә узган чараларның берсендә мондый программаларның әһәмияте турында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та әйтте.

– Ташламалы ипотека программалары халык арасында торак сатып алуга тотрыклы сорау барлыкка китерде. Күреп торабыз, узган ел белән чагыштырганда, 2023 елның ун аенда ил күләмендә ипотека кредитлары саны 61 процентка арткан. Хәзер Казанда ике бүлмәле фатирның уртача бәясе 12–13 миллион сум тора. Балалы гаиләләр арасында әнә шундый торакка ихтыяҗ зуррак, – диде Татарстан Рәисе.

Сер түгел, илдә яңа торакның 80–90 проценты ташламалы ипотека программалары ярдәмендә үз хуҗасын таба. Икенчел торак базарында әлеге күрсәткеч иллегә – илле чамасы, ди белгечләр. Узган ел нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Татарстанда яшәүчеләрнең банкларга ипотека буенча 539,7 миллиард сум бурычы бар. 2023 елның ун аенда гына да республикада 108 меңнән артык ипотека килешүе төзелгән. Үзәк банк мәгълүматларына караганда, ел азагында Татарстанда яшәүчеләр кредит оешмасыннан бурычны уртача 25 ел да 5 айга рәсмиләштергән. Бу – рекорд күрсәткеч. Чагыштыру өчен, 2022 елда ипотеканы күп дигәндә 23 ел да 8 айга алганнар.

«ДОМ.РФ» мәгълүматларына караганда, рәсмиләштерелгән барлык ипотекаларның 48 проценты «Гаилә ипотекасы»на туры килә. Әлеге программа башланган 2018 елдан бирле илдә яшәүче 800 меңнән артык гаилә шул рәвешле яшәү шартларын яхшырткан. «Гаилә ипотекасы» 2018 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр бала алып кайткан, шул ук чорда уллыкка бала алган, ике һәм аннан күбрәк балигъ булмаган бала тәрбияләүче гаиләләргә бирелә. Беренчел кертем күләме торакның 20 процентын тәшкил итә.

Соңгы арада ташламалы ипотека программаларына бәйле фикерләр шактый. Аларның кайберләрен туктатырга кирәк, дип әйтүчеләр дә бар. «Ташламалы ипотека халыкның торак сатып алу мөмкинлеген арттыру бурычын хәл итми. Киң колачлы ташламалы программалар өчен башка салым түләүчеләр, әлеге мөмкинлектән файдаланмаучылар да түли. Шуңа күрә ул адреслы, мәсәлән, гаилә, авыл, Ерак Көнчыгыш ипотекасы булырга тиеш», – диде шушы арада гына Россия Үзәк банкы башлыгы Эльвира Нәбиуллина.

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов фикеренчә, бүген фатир сатып алырга әзер булучылар күп калмаган инде.

– Үзәк банк 1 сентябрьдән кредит бирүгә бәйле таләпләрне катгыйлатты. Йорт яки фатир сатып алучыларның, беренчел кертемгә акча булмаганлыктан, куллану кредиты рәсмиләштерүләрен бик яхшы аңлыйбыз. Әйе, бүген без номиналь яктан да, реаль яктан да халыкның керем дәрәҗәсе артуын сизәбез. Тик бу икътисадның барлык өлкәләренә дә кагылмый. Нигездә төзелеш, сәнәгать кебек тармакларда эшләүчеләрнең хезмәт хакы артты. Ә бюджет тармагын алсак, айлык акча артса да, халыкның керем дәрәҗәсе шул ук, – ди белгеч.

Владимир ПУТИН,
Россия Президенты:
– «Гаилә ипотекасы» 2024 елның 1 июлендә тәмамлана. Хәзер Хөкүмәт аның киләчәге, шул исәптән программаны озайту турында уйлана. Әлбәттә, Хөкүмәт федераль бюджет мөмкинлекләреннән чыгып эш итәргә тиеш. Ничек кенә булмасын, «Гаилә ипотекасы»н озайту юнәлешендә фикер йөртергә кирәк дип саныйм.

Мондый шартларда бала тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм бигрәк тә кирәк. Яңалыкка риэлторлар да сөенә. Башкаладагы милек агентлыкларының берсендә эшләүче Әлфия Кәлимуллина әйтүенчә, «Гаилә ипотекасы»н озайтсалар, бүген кул җитмәстәй булып кыйммәтләнгән торакка бәяләр төшә башларга мөмкин.

– «Салават Күпере» торак комплексы янындагы Осиново бистәсендә төзелүче яңа йортта бер бүлмәле фатир 5 миллион сум тора. Казанның Яңа Савин районында исә искесе – 7–8 миллион сум чамасы. «Гаилә ипотекасы» алга таба озайтылса да, яңа йортлардагы фатирларга бирелүче ташламалы ипотека аерым категориягә караган кешеләргә генә калачак, дип уйлыйм. Ә төзүчеләргә ничек тә халыкны җәлеп итәргә кирәк. Шуңа күрә җәйгә таба торакка бәя төшә башларга ихтимал, – ди ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЧИРГӘ ЧИК ЭЗЛӘГӘНДӘ

Борчыган мәсьәлә

Республикада яман шеш очракларын вакытында табу да, әлеге мәкерле чирне җиңеп, тулы канлы тормыш белән яшәүчеләр саны да арта. Әмма тынычланырга ярамый, ди белгечләр. Яман чирдән саклану өчен исә гади генә киңәшләрне истә тотарга куша алар. Бөтендөнья яман шешкә каршы көрәш көне уңаеннан журналистлар белән очрашуга җыелган бер төркем белгеч шул хакта сөйләде.

Бүген республикада яман шеш белән 120356 чамасы кеше исәптә тора. Бер ел эчендә Татарстанда 5–6 ел дәвамында исәптә торучылар саны 5,4 процентка арткан. Арабызда яман чирне җиңгән, табиб күзәтүе астында тулы канлы тормыш белән яши торган кешеләр күбәйгән дигән сүз бу. Шулай да тынычланырга ярамый, ди табиблар. Әлеге чирнең исеме үк җисеменә туры килеп тора чөнки.

Татарстан Онкология диспансерының баш табибы Илгиз Һидиятов сүзләреннән аңлашылганча, узган ел җиңелләрдән булмаган. Баш табиб фикеренчә, бүген башкалага яңа онкология сырхауханәсе кирәк. Ник дигәндә, Казандагы онкология диспансеры бер сменага 300ләп кеше кабул итәргә тиеш. Чынлыкта бүген табиблар, ике смена эшләп, көненә 1 меңгә якын кеше кабул итәргә мәҗбүр.

– Шуңа күрә безгә яңа сырхауханә кирәк, – ди Илгиз Һидиятов. – Узган ел җиңелләрдән булмады. Шуңа да карамастан, узган елга куелган барлык максат-бурычларга ирештек. Яман шеш очраклары артты. Без тагын да җентеклерәк тикшергәнбез дигән сүз бу. Анңары узган ел диспансеризация, профилактик тикшерену күрсәткечләре яхшырды. Бу шуңа да бәйледер. Әлеге тикшеренүләр барышында бик күп яман шеш авырулары башлангыч чорда ук табыла. Быел да шундый рухта эшләрбез дип өметләнәм.

Баш табиб яшерми: баштарак кайбер төр медицина кирәк-ярагын кайтартуда кыенлыклар булган. Болар бар да Россиягә каршы кертелгән чикләүләргә бәйле.

– Әмма бу проблеманы тиз арада хәл иттек. Хәзер күбрәк Кытайдан кайтартылган җиһазлар белән эшлибез. Алар сыйфат ягыннан Европа, Америкада җитештерелгән аналогларыннан бер дә калышмый. Яман шешне дәвалаганда кулланылган дарулар кайтарту белән дә проблемалар юк. Чикләүләр аркасында базардан киткән оешмалар саны бармак белән генә санарлык. Алар җитештергән даруларның үзебездә җитештерелгән аналогларын куллана башладык, – ди Илгиз Һидиятов.

Узган ел Татарстанда күбрәк эчәклек (13,8%), тире яман шеше (13,5%), күкрәк яман шеше (12,8%), үпкә (8,1%), мәни бизе (6,9%), ашказаны (5,9%) яман шеше очраклары ачыкланган. Барлык очракларның яртысыннан артыгы (62,2 процент) башлангыч стадиядә табылган. Бер ел эчендә беренче стадиядә табылган яман шешләр 1 меңгә арткан.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш онкологы Эдуард Нагуманов моны республикада гомер озынлыгы арту, коронавирус аркасында кертелгән чикләүләрнең тулысынча бетерелеп, тормышыбызга диспансеризация кебек профилактик тикшеренүләрнең кире әйләнеп кайту нәтиҗәсе дип бәяли.

– Бер ел эчендә беренче тапкыр яман шеш табылу очраклары 1 мең очракка диярлек арткан. Мондый санның беркайчан да күзәтелгәне юк иде. Күрсәткечләрнең яхшыруы сөендерә, билгеле. Ләкин, икенче яктан, яман шешне ахыргача дәваларлык даруның әле дә булса уйлап табылмавы борчуга сала, – ди Эдуард Нагуманов.

Яман чирне кисәтү өчен исә белгечләр гади генә кагыйдәләрне үтәргә киңәш итә. Идел буе федераль округының һәм Татарстанның баш онкологы, Казан дәүләт медицина академиясе профессоры Рөстәм Хәсәнов фикеренчә, моның өчен, иң беренче чиратта, вакытында диспансеризация узарга кирәк.

– Яман шешне булдырмау өчен, сәламәтлекне яшьли кайгыртырга кирәк. Сәламәт яшәү рәвеше алып бару мөһим. Дөрес туклану, саф һавада йөрү – барысы да шуңа кергән. Диспансеризацияне дә вакытында узып торырга кирәк. Хөкүмәт тудырган менә дигән мөмкинлек бит ул. Әгәр кешегә, машинаңа бушлай техник хезмәт күрсәтәбез, дисәләр, елына бер түгел, өч барыр иде. Ә менә диспансеризация дигәндә, күпләр барырга атлыгып тормый, – ди баш онколог. – Шуңа күрә яман шешне кисәтү өчен алда телгән алган гади генә кагыйдәләрнең барысын да үтәргә кирәк. Моны синең өчен беркем дә килеп эшләмәячәк. Әнә шунысын да аңлау мөһим.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ИСЕ ЮК, ТӨСЕ ЮК – ЗЫЯНЫ КҮП

kzn.ru

СӨРЕМ ГАЗЫ БЕЛӘН АГУЛАНУ СӘБӘПЛӘРЕ

➤Төтен чыгу һәм вентиляция каналларының төзексезлеге.
➤Газ җиһазлары файдаланыла торган бинага җитәрлек һава кермәү.
➤Мәҗбүри суырткыч җайланмалар урнаштырып, вентиляция каналлары эшенә тыкшыну.
➤Кулланучылар тарафыннан газ куллану кагыйдәләрен аңлы рәвештә бозу (үз-үзенә кул салу максаты белән).

ГАЗ ЧЫГЫП ЯТМАСЫН ӨЧЕН НИШЛӘРГӘ?

✓Өйдән чыкканда, газны сүндерегез. Плитәсен генә түгел, газүткәргечтәге запас кранны да ябып куегыз.
✓Җиһазның ватык икәнен күрүгә үк, газчыларны чакыртыгыз.
✓Газ плитәсендә ризык әзерләгәндә, аны караучысыз калдырмагыз.

ГАЗ ИСЕ КИЛСӘ...

➤Электр җиһазларын кабызмагыз һәм сүндермәгез.
➤Тәмәке тартмагыз.
➤Тәрәзәләрне, ишекләрне ачыгыз, газүткәргеч кранын ябыгыз.
➤Урамга чыгыгыз.
➤04 телефоны буенча (104 – кесә телефоныннан) газ хезмәтен чакыртыгыз. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, бердәм 112 телефонына мөрәҗәгать итегез.

НИЧЕК САКЛАНЫРГА?

Өйләрдә электр магнит клапаны белән ябылган газ сигнализаторлары урнаштырырга кирәк. Алар, метан һәм сөрем газы чыгуга, газ килү юлын автомат рәвештә ябып куя. Болай эшләү газ чыгуын, төтен һәм җилләтү юлындагы җитешсезлекләрне вакытында ачыкларга ярдәм итәчәк.

Сак бул!

Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгыннан алынган мәгълүматлар буенча, узган ел сөрем газы белән агулануның 49 очрагы теркәлгән. 103 кеше зыян күргән, шуның 53е – балалар. «Газпром трансгаз Казан» оешмасының баш инженеры Алмаз Ханнанов агулану очракларының сәбәбен су җылыту җиһазларын дөрес кулланмауга, вентиляция һәм төтен чыгу юлларының төзек булмавына бәйләп аңлата.

– Үзегез ишетеп-белеп торасыз, күпме генә сөйләнсәк тә, кисәтсәк тә, газ куллануга бәйле күңелсез хәлләр артып тора. Аеруча ягу сезоны һәм салкыннар башлангач, сөрем газы белән агулана башлыйлар. Әгәр дә абонентлар көнкүрештә газ куллану кагыйдәләрен үтәгән булса, бу бәхетсезлекләр булмас та иде. Күп очракта сөрем газы белән агулану газ колонкасы урнаштырылган иске йортларда килеп чыга, – ди Алмаз Ханнанов.

Белгеч әйтүенчә, газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтүне елга бер тапкыр үткәрергә кирәк. Күп кенә мәсьәләләр нәкъ менә планлы тикшерү үткәргәндә ачыклана һәм хәл ителә, ди ул.

– Техник хезмәт күрсәтү өчен йортларга һәм күп кенә фатирларга керә алмыйбыз. Йә алар анда яшәми, йә инде ишекләрен ачмыйлар. Кайбер очракта фатир хуҗасы алышына, ә безгә бу хакта хәбәр бирүче юк. Тагын шунысы бар: яңа хуҗа көнкүрештә газ куллану кагыйдәләре белән дә танышмаган булып чыга. Шуннан чамалагыз инде. Андый кешеләр газ колонкасы белән дә, су җылыту җиһазы белән дә файдалана белми. Беләм дип уйласа да, дөрес кулланмый. Фатирга вакытлыча кеше кертеп торучы хуҗалар, газ колонкасы кулланган очракта, кунакларга кагыйдәләрне искәртергә тиеш, – ди баш инженер.

Алмаз Ханнанов әйтүенчә, Татарстанга кунакка килгән туристлар да сөрем газы белән агулана икән.

– Күп кенә фатирларда газ колонкасы ярдәмендә су җылыталар. Тәрәзә ачмыйлар, өйдәге һаваны бетерәләр. Кеше агуланмый нишләсен инде? Тагын шунысы да бар: күпләр су җылыткычны үзләре алыштыра. Аны тоташтырганда газ белән су торбасын бутыйлар. Бу, бер яктан, бөтен йорттагы газны сүндерә, икенчедән, торбаларга су тулып, кышын шартлый. Ә бит килгән зыянны абонент түли. 2 мең сум акча түләп газ оешмасы хезмәткәрләренә алыштыртмыйлар да, аннары килгән зыян өчен әллә ничә мәртәбә күбрәк акча түлиләр, – ди белгеч. – Татарстанда яшәүче һәр абонент белән килешү төзелгән. Аларга бары тик безнең оешмага шалтыратып гариза гына калдырырга кирәк.

Алмаз Ханнанов, фатирларга газ чыгу турында хәбәр бирә торган җиһаз куеп та гомерләрне саклап була, ди.

– Бу җиһаз автомат режимда метан һәм сөрем газы булу-булмавын контрольдә тота, алар рөхсәт ителгән чикләрдән артып киткәндә тавыш бирә һәм газ керүне туктата. Соңгы елларда әлеге система урнаштырылган биналарда күңелсез хәлләр килеп чыкмады. Теләгән кеше бу җиһазны газ хезмәткәрләре аша куйдырта ала, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Уйлы күңел уйлана

КЕМДӘ – СЫЕР КАЙГЫСЫ, КЕМДӘ...

Кечкенә авылда яшәүнең бер минусы бар: үзеңәме, малыңамы дару кирәк булса, район үзәгенә барырга туры килә. Безнең үзебезгә, мәсәлән, даруханәнең иң якындагысы – биш чакрым ераклыктагы авылда. Дөрес, күрше авылдагы кибетнең бер почмагында ветеринария даруханәсе бар, әмма анда сиңа кирәкле бөтен дару-препаратлар да булмый. Бигрәк тә дару дигәнең песиләр-этләр өчен булса.

Шушы арада ветаптекага йомыш төште. Керсәм, миннән алда чиратта ике кеше бар. Иң алдагысы бер-бер артлы сыерының моң-зарларын әйтә тора (аягы, тоягы, җилене һ.б.), сатучы ханым, аңлата-аңлата, даруларны бирә тора.

– Сыерыбызның мөгез арасындагы йоны коелды, нәрсәдән икән ул? – дип, чираттагы соравын бирде һәм нәрсә, ничек икәнен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде сатып алучы.

– Нигә фотога гына төшереп алып килмәдегез соң? – ди сатучы.

– Анысы уйга да килмәгән шул. Ветврачны чакырган идек, лишайга охшаган да, охшамаган да диде, нәрсә дияргә дә белмәде...

– Ул дәрестә булмаган инде алайса, – диде уен-көлкеле сатучы ханым (сүз уңаеннан, бөтен кешегә ачык, бик аралашучан булып чыкты әлеге мөлаем ханым). Көлештек. Тыңлаганда гына кызык шул бу тема. Сыерсыз калуыбызга беренче тапкыр сөенеп куйдым. Барысы да баштан үткән, мөгезеннән тоягыннан чаклы авыру-проблемалары барысы таныш... Түзмәдем: «Кешедә – сыер кайгысы, миндә – песинеке, – дим, үземнән алда торучы хатын-кызга, кулымдагы дарудан бушаган коробканы күрсәтеп. – Әйтергә дә уңайсыз...»

Коробкама күз салды да ул көлеп җибәрде:

– Миндә дә шул проблема...

Сүз стерильләтмәгән ана песиләр проблемасы турында иде. Туганнарым күпме генә: «Барыбыз да операция кичердек, үзең дә... бер авыртыр да ул да тынычланыр, үзең дә», – дисәләр дә, операция ясатырга җәллим шул пескәйне.

Ниһаять, беренче ханым үзенә кирәкле даруларны алып бетергәч, миннән алдагы ханым: «Сез бер генә дару алсагыз, әйдә, алып китегез, минем сорауларым күп әле», – дигәч, коробкамны сатучыга сузам.

– Төймәлесен бирегез әле. Анысы эчертергә уңайрак.

– Сыегы да, төймәлесе дә калмады шул әле, бүген килергә тиеш, кичкә таба кереп карагыз...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сөендем әле, бер без генә юктан бар иткән проблема артыннан йөрмибез икән, бу даруны кулланучылар күп икән, дим. Шул ук вакытта стерильләтүчеләр дә күп икән, өйгә килеп эшләүче дә бар, диделәр. Бәлки тәвәккәлләрмен дә әле дип уйлап куйдым...

Килгән килеш буш чыкмыйм инде дип, декабрьдә туган песи балаларына муенчак сорадым.

– Элек декабрьдә бәбиләми иде песиләр... Мартта гына шаярышалар иде, алар да бозылды, хәзер ел әйләнәсе бәбилиләр, – ди чираттагы ханым.

– Әнә шуңа күрә авылларда хәзер өй саен унар песи, – мин әйтәм.

– Нәрсә дип җыясыз аларны? Тугач та, күзләре ачылганчы чиләктәге суга батырсаң ярый икән бит аларны, – дип, сүзгә кушыла бездән артта чиратын көтүче өлкән яшьтәге ир-ат.

– Үлгәч, ул песиләр өчен җавап бирәсе дә бар бит әле, – дим.

– Ни йөрәгең белән аларны үтермәк кирәк, унөчтән артмый алар, унөчкә тулгач, берәм-берәм юкка чыгып бетәләр, – ди икенчебез.

– Ачлык заман түгел бит. Песиләргә бирергә генә ризык җитәрлек, – дип, даруханәдән чыккач та, күңелемнән әлеге абый белән бәхәсләшәм.

Аннан ерак түгел бер кибеткә кереп, әлеге дә баягы песиләргә ризык, туалетларына салырга прессланган пычкы чүбе алырга булдым. Алары да кечкенә авыл кибетендә юк. Шуңа күрә барган килеш дип күбрәк алырга тырышам. Ә алар шактый бәһале (башкасын ашамый, әле аларын да талымлый өйдәге песи). Кассир: «Апа, чек кирәкме?» – дип сорагач, башта кирәкми дигән идем. Аннан кире уйладым: «Бирегез әле, кайткач, песигә күрсәтәм...»

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Авыл җаны

Әкиятче әби

Чаллыдан ерак булмаган җырлап торган исемле Күзкәй авылында «әкиятче әби» – Флера Мәрданова яшәп ята. «Тавыклары да җырлый торган» Казан артында туган кыз, кияүгә чыгып, бу авылда яши башлавына да озакламый ярты гасыр була. Сүз уңаеннан, талантлы шагыйрәбез Лилия Гыйбадуллина да – Күзкәй килене.

«Әкиятче әби» диюем «шыттыра» мәгънәсендә түгел, гәрчә сөйләшергә бик ярата Флера апа. Аны тыңлый башласаң, татар теленең һәр сүзенә бәйле берәр хикмәт, берәр хатирә ишетерсең кебек; сүз йомгагы һич туктамый тәгәри дә тәгәри... «Әкиятче» диюемнең сәбәбе: ул, чынлап та, әкиятләр яза. Ун китабының күбесе – әкиятләр. Шигырьләре дә халыкчан, матур; хикәяләре дә гыйбрәтле («Казан утлары» журналында берничә ел рәттән җиңү дә яулаган ул), ә шулай да аны бу якларда әкиятче булалрак беләләр. «Мәйдан» журналында эшләгән Рәшит абый Бәшәр фатихасы белән, «Мәйданчык» кушымтасына әкиятләр кирәк булганга яза башлаган ул аларны. Күп китапларын үз акчасына чыгара, аннары аларны китапханәләргә, мәктәпләргә, балалар бакчаларына өләшеп чыга. Үзенең туган ягы Арчада да аның һәр китабын көтеп торалар дип беләм. Китап тузан җыеп ятарга тиеш түгел, кешегә файдасы тисен, дип чыгардым бит мин аларны, ди ул.

«Көмеш кыңгырау» газетасында эшләгәндә, Күзкәй мәктәбенә дә килеп чыккан идек. Соңыннан, әлбәттә, кунакчыл Флера апа янына да сугылдык. Аның өе дә үзе кебек үзенчәлекле. Дөресрәге, берсе заманча, икенчесе – безнең әбиләр чорындагы агач өй. Икенчесе – Флера апаныкы гына! Ул музей-йорт шикелле: элеккеге өйләрнең нинди булуын күрергә теләсәң, рәхим ит, биредә бар да бар. Чигүле мендәрләр, сандык, кашагалар, чып-чын, ап-ак итеп акшарланган мич, табалар, табагачлар... Бу өйдә дә, Флера апаның үзендә дә әллә никадәр сер, тарих бар. Флера апа бик тәмләп һәм озаклап биредәге һәр җиһаз турында сөйли ала. Җиде тәбе дә тора анда; тычкан тотып, мәчеләремне сыйлыйм, затлы токымнан бит, көтеп торалар, дип көлә ул.

Үзе аралашкан, күргән-белгән каләм әһелләре турында да әллә никадәр истәлекләре бар аның. Ә аралашкан кешеләре бик кызыклы. Шәүкәт Галиев кенә дә ни тора! Ул аларның гаилә дусты булган. Ә Рәфикъ Юнысны «Мине әдәбиятка этеп кертеп җибәргән кеше иде», – ди. «Үз эшенә гаҗәеп дәрәҗәдә бирелгән кеше иде», – ди аның турында. Мине тыңлаганда күзләрен йомып тыңлый иде, ник дисәм, ул шулай күзләрен ял иттергән икән, баш күтәрми эшли иде бит, ди. Күзкәй мәзәкләрен «Идел» журналы өчен Рәфикъ Юныс тәкъдиме белән яза башлаган.

Флера апаның буш вакыты юк. Җиденче дистәне тутыруына карамастан, зур бакчаны да карый ул, кул эшләре, аш-су хикмәтләрен дә яхшы белә. Мин соңгы тапкыр сөйләшкәндә, алма, кара җимешләр белән каз тутырып әвәрә килә иде. Ә яңа өйләренең диварларында чиккән, алмаз мозаикасы белән эшләгән әллә никадәр картиналарын күреп сокланган идек. Бакча тутырып алмагач, башка җиләк-җимеш агач-куаклары үстерәләр. «Хәзер авыл мәзәкләрен җыясыңмы соң?» – дигән соравыма да: «Корт та җиләк-җимеш кенә җыям инде хәзер», – дип көлде ул. Бернәрсәне дә исраф итми. «Бакчабыз тулы кош-корт», – ди. Аның кошлар ашатып мәш килүен белгән күршеләре дә, мал суйгач, аларга туңмай кертә.

Флера апа – йөремсәк кеше, юмарт кеше. Якын-тирәдәге мәктәпләр, китапханәләрдә ул – еш кунак. Туктамыйча, сәгатьләр буе сөйли ала. Үзе белән һәрвакыт бүләк, күчтәнәчләр – китап, тәм-томнар ала.

«Күзкәйдә нинди кешеләр яши, Флера апа?» – дим. «Җырчы да биюче, намазга сирәк йөрүче», – ди җор телле апам. «Туктагыз әле, – мин әйтәм, – Күзкәй балаларына дини тәрбия бирүче җәйге лагерь турында язган идек бит». «Әбиләре укымаганга бәбиләрен укыталар хәзер», – ди Флера апа. Һәм авылларындагы Илнур хәзрәтнең бик саваплы эшләре турында сөйләп китә. Үзе дә намаз укый, һәрвакыт догада. Муллалар нәселеннән ул. Шулай да без күреп гадәтләнгән ак яулыклы намазлы карчык кыяфәтендә түгел ул; иман киемендә түгел, калебеңдә, дип саный. Тагын бер «сәер» ягы бар (безнеңчә булмаган бар нәрсә сәер бит инде) Флера апаның: аның төшләре алдан хәбәр җиткерәләр. «Рәфикъ Юныс аларны җыеп бастырырга да җыенган иде», – ди Флера апа.

Язмам ахырында Флера апа сөйләгән бер мәзәкне язып китим әле. Ык елгасына гаилә белән коенырга барган булганнар. Флера апаның каенанасы ике аягына да бала-чаганың кечкенә резин түгәрәкләрен кигән дә суга кереп киткән. Әллә кызык ясыйсы килгән, әллә уйлап бетермәгән. Эчкә керүгә, түгәрәкләр өскә күтәрелгән дә әбекәй башы белән суга чумган. Чүт кенә батмый калган. Шуннан бер мәзәк сөйләгән. Авылларындагы Фәлән Фәлән улы беренче тапкыр мотоциклга утырган да бик кызу гына кузгалып киткән икән. Тик матайны кабыза белсә дә, туктата белми икән бу. «Коткарыгыз, атагыз кирәк булса!» – дип кычкыра икән артыннан йөгергән малайларына. Салам кибәненә чумып кына туктый матай.

Менә шулай: тәгәри китте йомгагым... Флера апа Мәрдановaның бер китабы да шулай атала. Гомер йомгагы озак тәгәрәсен әле әкиятче әбинең: андый шәхесләр тормышны кызыграк, үзгәрәк, мәзәгрәк итәләр.

Лилия ФӘТТАХОВА

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Хөппениса карчык

Вагыйз Шәйхетдинов картинасы / artnow.ru

Әле кибет янында афиша күреп кайттым. Әллә нинди бер җырчы безнең авылга концерт белән килергә җыена икән. Тамагына чуан чыккыры нәрсә. Тормыш болай да авыр, көн-таң атса, кот алынып тора, ә бу адәм ыстырамнары шундый чорда авыллар буйлап кәеф-сафа корып, сикергәләп йөрергә чыккан. Ишшу җитмәсә, бушлай да түгел бит әле ул. Билет хакы фәлән кадәр тора. Их, хәлләрең булып, имән себерке белән куып җибәрергә шуларны. Бүтән сару кайнатып йөрмәсләр иде.

Район гәҗите кыстырып киткәннәр менә. Элегрәк, почта чыгымнарын киметәбез дип, айга бер генә китереп китә торганнар иде. Хәзер, Аллага шөкер, ике тапкыр килә, яңалыклар белән танышып барабыз. Районда хоккей буенча ярыш үткәргәннәр икән. Башка авыл командасы беренче урынга чыккан, безнекеләр катнашмаган. Дөрес эшләгәннәр. Тырай тибеп, шар сугып йөри торган дәвермени! Тормыш болай да авыр, көн-таң атса, кот алынып тора, ә бу адәм ыстырамнары кәшәкә сугарга җыелган. Алай бик көч-гайрәтләре ташып торса, илне сакларга китсеннәр әнә. Их, хәлләрең булып, кәшәкәләрен тартып алып, сыртларына салырга. Бүтән алай кыланып йөрмәсләр иде.

– Хәерле көн, балам, хәерле көн. «Хәлләр ничек?» – дип, кешенеке кебек инде. Әле эштән кайтып киләсеңмени? Кая ашыгасың шу…

Эш, имеш… Эш ул колхозда, маллар арасында я иген кырында була. Ә синеке – шабашка. Йорттыр-сарайдыр төзегән булып йөрисез дә умырып акча аласыз. Элекке заманда утыртып куярлар иде сезне. Әлегә сезнең кайгы юк җитәкчеләрдә. Тормыш болай да авыр, көн-таң атса, кот алынып тора, ә бу адәм ыстырамнары кешеләргә йорт салып йөри, абзар төзи, мунча, койма тота. Шуның ише чүп-чар белән булаша торган заманмыни?! Башта илең турында уйла, аннан көнеңне хәстәрләрсең. Юк инде, юк… Балта түтәсе белән башларын төйсәң дә, аңлый торган нәрсә түгелләр.

Әнә тагын бер эшем иясе кайтып килә инде. Пикәрнәйдә йөри ул, ипи сала. Безнең дә яшьлек булды инде, ипи салыр өчен генә әллә кая чаклы барып йөрмәдек. Тоттык та салдык үзебезнең өйдә. Ашап туйгысыз була торган иде. Кибеттән ипи алсак та, ихатадагы мал-туарга гына алдык. Шулар гына ашый торган иде кибет ипиен… Хәзер барысы да шуны ашый… Адәм ыстырамнары… Пикәрнәйдә ипи сала торган дәвермени инде…

Әй, Ходаем, бу күгәрченнәргә нәрсә җитми икән инде?! Өй кыегына кунганнар да азгын тавыш белән гөр-гөр килешеп утыралар. Пар күгәрченнәр, имеш. Үзебезнең якныкы түгелләрдер әле, әллә кайдан качып килгәннәрдер. Хәзер бит күгәрченнәренә кадәр эмигрант, җайлы җир эзләп йөриләр. Үзебезнеке түгел, канишны, әнә тегесенең күзе кысык, монысының томшыгы – Арарат биеклеге. Үзебезнекеләр болай кыланмас иде. Ил турында уйлыйсы урынга шулай интим тавыш чыгарып, нәрсәгәдер ишарәләп утыралармыни?! Кош-корт ыстырамнары!

Элегрәк бер дә болай булмый торган иде. Бөтен авыл гөрләп тора, кая гына барсаң да күңелле, юктан да кызык таба иде халык. Хәзер әллә нишләде дөнья. Нәрсәгә генә күз салсаң да, эчпошыргыч күренешкә тап буласың.

И, болай итеп канымны бозып торганчы, кереп телевизорымны карыйм әле. Тормышның бердәнбер рәхәт җире әнә шул телевизор алдындагы утыргычта бит. Нәрсә генә карасаң да, күңелгә хуш килә. Гел без күрергә теләгән нәрсәләрне күрсәтәләр, без ишетергә теләгәннәрне сөйлиләр. Әллә бу дөньяда телевизордан да әйбәтрәк бер кеше дә калмаган ул…

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ЗАТЛЫ ТАМАША

Концерттан соң

Яраткан тамашачысын елга бер җыеп, гел шулай сөендереп тора ул. Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов шушы көннәрдә 69 яшен билгеләп үтте һәм матур гадәт буенча тамашачысына туган көн концерты уздырды.

tatar-inform.ru

Тамашачыга мондый җыр-моңлы, шигъриятле концертлар тансык. Айдар Фәйзрахмановның ел саен туган көн концерты уздыруы һәм халыкның ел саен залны тутырып килүе әнә шул хакта сөйли. Халык өч сәгатькә якын барган тамашаны тын да алмый карап утырды. Урынында елмаеп, урынында елап алды. Апалар һәм әбиләр генә түгел, олы яшьтәге абыйлар да күз яшен сөртеп утырды хәтта.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең «Олы юл әйтте» циклындагы концертларны Айдар Фәйзрахманов 2016 елдан башлап тәкъдим итеп килә. Быелгысының исеме «Утырып уйлар уйладым» иде. Аның концертлары шунысы белән үзенчәлекле: монда милли моңнарыбызны, матур җыр-биюләрне тыңлап-карап кына түгел, үзе башкаруында күренекле шагыйрьләребезнең әсәрләрен дә ишетеп була. Шигъриятебезне сәхнәдән үтемле итеп халыкка җиткерә белә Айдар абый. Сүз кадерен белүче сирәк сәхнә осталарының берсе ул. Бу кичәсендә ул Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Разил Вәлиев, Кадыйр Сибгатуллин һәм башка әдипләрнең шигырьләрен сөйләде.

Җырчыларның да «иң-иң»нәре генә иде монда. Филүс Каһиров, Алинә Шәрипҗанова, Айгөл Хәйри, Сиринә Зәйнетдинова, Илгиз Мөхетдинов, Рөстәм Насыйбуллин, Алинә һәм Азат Кәримовлар. Яшь җырчы Динар Шәрәфетдиновның чыгышын аеруча җылы кабул иттеләр, бик озак алкышладылар. Күңелләрне нечкәрткән мизгел – Айдар абый кызлары Чулпан һәм Айгөл белән бергә «Мин сине шундый сагындым» җырын башкаруы. «Әниләренең һәм минем ике газиз бөртегебез», – диде ул кызлары турында.

Ансамбльгә – 25

Үзе моңлы, үзе заманча. Айдар Фәйзрахмановның туган көн концерты фольклор музыкасы дәүләт ансамбленнән башка узса, сәер булыр иде. Сүз уңаеннан, быел ансамбль оешуга 25 ел тула. Ел әйләнәсе халыкка рухи азык таратучы, халык җәүһәрләрен дөньяга танытучы алар. Дәүләтнеке булса да, аны халык та, яратып, Айдар Фәйзрахманов ансамбле дип йөртә. Коллективтагы һәр артист җырлый да, бии дә, музыка коралларында да уйный. Бию-хәрәкәт, сәхнәдәге төсләр балкышы, купшы киемнәр, һәрберсе төгәл хәрәкәтләр – бер җепкә тезелгән мәрҗәннәр шикелле бу егетләр һәм кызлар. Шул дәрәҗәдә бербөтен, бер йодрык булып эшлиләр-яшиләр. Айдар абый аларга яратып «балаларым» дип дәшә.

– Бүген югары уку йортларында фольклор ансамблендә эшли торган универсаль артистларны тәрбияләү өчен факультетлар, хәтта бүлекләр дә юк. Чөнки алар камил рәвештә бии дә, җырлый да, сәхнә юнәлешләрен дә белергә, ниндидер уен коралында уйнарга да тиеш. Бу мәсьәләдә фольклор ансамбль үзенә күрә бер мәктәп булып тора. Алар миңа йә җырчы, йә биюче, йә музыкант буларак килә. Без һәр көнне икешәр сәгать шөгыльләнәбез, камилләшәбез. Биш елда камил дәрәҗәгә җитәләр. Бу – бик зур хезмәт. Бүген без – бу юнәлештә камил рәвештә эшләүче бердәнбер коллектив. Нәтиҗәбез һәм алга таба барыр юлыбыз да бар, – ди Айдар Фәйзрахманов.

Ләйсән САФИНА

ПЕНСИЯ АКЧАСЫНА – КИТАП

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ӘДИБЕ ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА – 145 ЕЛ

culture.ru

Татарның төп театры ни сәбәпле Галиәсгар Камал исемен йөртә? Җавабы бик гали дә, гади дә, чөнки бөек әдибебез «татар театры атасы» дигән хөрмәтле исемгә лаек. Шуңа күрә аны бөтен кеше, хәтта балалар бакчасына йөргән балалар да яхшы белә, дигән фикер ишетелде «XX йөз башы татар яңарышы һәм Галиәсгар Камал» дип аталган «түгәрәк өстәл»дә. Бу чараны Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты үткәрде.

Хезмәтенә күрә хөрмәт… җитеп бетми

Сүз дә юк, театр шулай аталгач, Галиәсгар Камалны, чынлап та, белмәгән кеше юктыр да. Ә менә әдибебезнең иҗаты, тормышы җитәрлек өйрәнелгәнме? Эшенә күрә бәясен бирә алганбызмы? Тиешле хөрмәтне күрсәтәбезме без аңа? «Түгәрәк өстәл»дә шундый сорауларга җавап эзләнде. Нәтиҗәдә, эшләнәсе эшләр күп әле, дигән фикергә килделәр.

Өстәл янында утыручыларны бигрәк тә Галиәсгар Камалның энесе Габдрахманның улы Искәндәр Камалов чыгышы уйга салды бугай.

– Галиәсгар абыемның балалары белән бик аралашып яшәргә туры килмәде, – диде ул. – Мин 1938 елда туганмын. Яшь аралары шактый зур иде. Башта ничектер дөнья мәшәкатьләре белән игътибар да җитеп бетмәгәндер. Абыебызның архивы белән 1996 елда ныклап шөгыльләнә башладым. Бик күп китаплар укыдым. Шуларның берсендә 1923 елда Галимҗан Ибраһимов: «Галиәсгар Камалның тормышы бик кыен, аңа ничектер булышырга кирәк», – дип яза. Мин булдыра алган кадәр аның иҗаты турында мәгълүматлар туплап, тирәнтен өйрәнергә тырыштым, юбилее уңаеннан пенсия акчама китап әзерләдем. Сезгә дә бүләк итеп алып килдем. Кызганыч, акча җитмәү сәбәпле, 50 данә генә чыгарырга туры килде. Язу ягыннан, әлбәттә инде, әллә ни талантым юк. Шуңа күрә филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗановтан ярдәм итүен үтендем.

Китапның пенсия акчасына чыгарылуы турында сүз чыккач, залда уңайсыз тынлык урнашты. Сүзне Фоат Галимуллин дәвам итте:

– Без, бигрәк тә Искәндәр абый чыгышыннан соң, Галиәсгар Камалга карата игътибар җитмәвен күрдек. Аның хакында әллә кайчан затлы альбомнар чыгарырга вакыт бит югыйсә. Мондый китап чыгару – Искәндәр абыйның батырлыгы, әлбәттә. Әмма оялып торырга түгел, тиешле оешмаларга барып, чаң сугарга кирәк булган да бит. Кем аңа каршы килер иде икән? Тик татарны күп вакытта тыйнаклык харап итә шул.

Бу җәһәттән тәкъдимнәр дә булды. Беренчесе – 2025 елда (чөнки быелга инде план төзелгән), Галиәсгар Камалны фикер иясе, драматург, журналист буларак ачып, «Җыен» нәшриятында бик затлы, эчтәлекле китап чыгарырга. Әзерлек эшләрен бүгеннән үк башларга. Чарада катнашучылар, бу китап яңа театр бинасы ачылышына да зур бүләк булыр иде, диештеләр. Икенче тәкъдим исә яңа бина ачылуга бәйле. Анда музей яки башка берәр исем белән аталган урын булып, Галиәсгар Камалның тормышын, иҗатын күрсәткән экспонатлар куясы иде дигән фикергә килделәр. «Түгәрәк өстәл»гә җыелган галимнәр, журналистлар: «Без бүген Галиәсгар Камалны яңача ачтык. Бу сөйләшү бик вакытлы булып, уйланулар өчен этәргеч бирде», – дип таралыштылар. Сөйләшүдә Камал театрыннан беркемнең дә булмавын гына аңлап бетермәделәр. Югыйсә чакыру булган икән.

Журналист

«Түгәрәк өстәл»гә журналистларның чакырылуы әйтелгән сүзләрне массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен генә түгел иде. Галиәсгар Камал – каләм ияләре өчен дә чын остаз, юл ярып баручы. Бу хаклыкның да төбенә төшәргә тырыштык.

Каенатасы Садыйк бай белән әтисе Галиәкбәр агай, Галиәсгарның муллалыктан баш тартуына аптырап, аны сәүдәгәр итү фикеренә киләләр һәм китап кибете ачып бирергә булалар. Шулай итеп, 1901 елны «Мәгариф» исемле китап кибете ачыла. Ләкин Галиәсгарның төп теләге табыш алу булмый, ул монда әдәби әсәрләр, газета-журналлар һәм уку әсбаплары сата. Истанбулга да барып, аннан төрек әдәбияты алып кайта. Шул вакытларда Германиядән полиграфия эшенә өйрәнеп кайткан Мәхмүт Алмаев белән, гектографта басып, «Тәрәккый» исемле «идән асты» газетасы чыгара башлый һәм шәкертләргә тарата.

Тора-бара Галиәсгар Камал рәсми рәвештә газета чыгару эшенә төшенә һәм 1906 елдан башлап Габдулла Апанаев дигән Казан мулласы белән «Азат» исемле газета чыгара башлый. Ләкин алар идея ягыннан килешә алмыйлар. Камал аның белән акча кирәк булганга гына эшләргә мәҗбүр була. Шуңа күрә газетада каршылыклы язмалар күп басыла. 56 номер чыкканнан соң, Габдулла мулла газетаны ташлап китә. Камал, газетаны үз җаваплылыгына алып, «Азат халык» исеме белән чыгара башлый. Ул беренче номерыннан ук сул фикерле газета булып чыга башлый, татар эшче-крестьяннарының сыйнфый аңын уятырга тырыша һәм шул рәвешле «Йолдыз», «Вакыт» кебек буржуа газеталарына каршы көрәш ача. Бу газетага Хөсәен Ямашев кебек татар большевикларының турыдан-туры катнашы була. Шунлыктан патша цензурасы нык игътибар биреп, аерым номерларын чыгаруда зур тоткарлык ясый. Ахыр чиктә мөхәррирнең 15 нче номерда язылган баш мәкаләсе өчен газета конфискацияләнә, Галиәсгар Камал үзе судка бирелә. Ирегеннән мәхрүм итәргә дигән карар 100 сум штраф белән алмаштырыла. Камал «Казан мөхбире» газетасында эшли башлый. Тик аның мөхәррире, помещик Сәетгәрәй Алкин белән килешә алмыйча, «Йолдыз» газетасына китә. 1908 елда, Тукай белән бергәләп, «Яшен» исемле көлке журнал чыгара башлый. Журналның редакциясе Камалның үз фатирында булып, ул рәсем һәм карикатураларны үз кулы белән ясый. «Яшен» тукталганнан соң, яңадан «Йолдыз»га килә. 1912 елда Балкан сугышы вакытында ул Төркиягә махсус хәбәрче итеп җибәрелә. Ләкин аннан авырып кайтып, озак вакытлар дәваланырга туры килә.

Галиәсгар Камал үз гомерендә барлыгы 102 исемдә сәхнә әсәре яза. Иң соңгы сәхнә әсәре булып 1933 елда язылган «Өч тормыш» исемле пьесасы исәпләнә.

Октябрь революциясеннән соң Галиәсгар Камал, һич тә икеләнмичә, халык өчен хезмәткә күтәрелә. Казан губернасы Башкарма комитеты тарафыннан чыгарылган «Эш» газетасында, 1921 елдан соң «Татарстан хәбәрләре», «Кызыл Татарстан» (бүгенге «Ватаным Татарстан») һәм «Крестьян газетасы»нда эшли. Шул ук вакытта театр һәм драмтүгәрәкләр белән дә арасын өзми.

Драматург

1906 елның көзендә татар яшьләре Казанда беренче мәртәбә халык өчен ачык спектакль куярга җыеналар. Сәхнәгә чыгарыр өчен Галиәсгар Камал тарафыннан төрекчәдән тәрҗемә итеп бастырылган «Кызганыч бала» әсәрен сайлыйлар. Камал бу спектакль өчен кирәк булган афишаларны үзе кулдан яза һәм билетлар сату эшен оештыра. 1907 елда «Сәйяр» труппасы төзелгәч, артистлар өчен киемнәр табыша, вакыт-вакыт режиссерлык та итә. Энеләре Габдулла белән Габдрахман Камалларны да шунда кертә. Труппаны яңа спектакльләр белән тәэмин итү эшенә керешә.
1908 елда үлемсез «Беренче театр» комедиясен бастырып чыгара. Бер-бер артлы «Бүләк», «Уйнаш», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», «Өйләнәм – ник өйләндем» спектакльләре дөньяга чыга. Күп әсәрләре кульязма хәлендә уйналып йөртелә. Татар дәүләт драма театры төзелүгә, анда профессиональ артист булып эшли, җаваплы рольләрне башкара. Пенсиягә чыккач, Наркомсобес клубына йөреп, сукырлар өчен драмтүгәрәк оештыра, алар өчен «Күзсез мастерлар» дигән пьесасын яза. Соңгы көннәренә кадәр кулыннан каләмен төшерми.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Галиәсгар Камалга 1923 елда «Хезмәт батыры», 1929 елда, Татар театрының 20 еллык бәйрәме уңаеннан, «Татарстан халык драматургы» исеме бирелә. Әдипнең туында 60 ел булу уңаеннан, Казандагы Татар дәүләт академия театрына Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм ул туган элекке Фуксовский урамына Галиәсгар Камал исеме бирелә һәм шул урамдагы ул туган йортка мемориаль такта куела.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Карлар да белми

Әкрен генә җиргә карлар төшә, –
Капланалар эзләр.
Күңелләрдә ләкин уелып кала
Үткән елгы сүзләр.

Әкрен генә җиргә карлар төшә, –
Ап-ак чәчәк гүя.
Көтелмәгән түбә-үрләренә
Көмеш таҗлар куя.

Әкрен генә җиргә карлар төшә, –
Керә алмый җанга.
Җиргә салган эзләр яңаралар,
Яңару юк җанга.

Әкрен генә җиргә карлар төшә, –
Тапталасын белми...
Җирдән кабат күккә ашкач кына
Акланасын белми...

Нәҗибә САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Спас районының Иске Рәҗәп авылында яшәүче кадерле укытучыбыз, гомерлек киңәшчебез, олы җанлы, киң күңелле остазыбыз **Гаммар Фәйзи улы ФӘЙЗИЕВ** 11 февральдә үзенең гомер бәйрәме – 90 яшьлек юбилеен бәйрәм итә.

Хөрмәтле Гаммар ага! Без, сезнең укучыларыгыз, мәктәпне тәмамлаганнан соң кайларда гына эшләсәк тә, сезнең күңел җылыгызны тоеп, хәзерге көнгә кадәр рәхмәтле булып яшибез! Авылыбызның иң күркәм, ихтирамга лаек кешесе буларак, һәр яктан Сездән үрнәк алабыз.

Озак еллар дәвамындагы намуслы хезмәтегез өчен Россия Федерациясе һәм Татарстанның югары бүләкләренә лаек булдыгыз!

Тормыш иптәшегез, озакламый үзе дә 90 еллык юбилеен бәйрәм итәргә җыенучы кадерле укытучыбыз Мәсгудә апа белән тату, үрнәк гаиләдә 65 ел бергә гомер итүегез дә күп нәрсә турында сөйли. Фәйзиевләр династиясенең укытучылык буенча гомуми эш стажы 350 елдан артуы белән хаклы рәвештә горурланырлык!

Олуг юбилеегыз котлы булсын! Безне шатландырып, киләчәктә дә бергә-бергә яшәргә язсын! Сезгә исәнлек, саулык телибез.

Республиканың төрле почмакларында яшәүче күпсанлы укучыларыгыз.

Әлеге теләкләргә кызыгыз Әлфия, улларыгыз Рафаэль белән Илнар, кияү-киленнәрегез, оныкларыгыз, барлык авылдашларыгыз кушыла.

ЮЛЛАР – ШАТЛЫК АНЫҢ ӨЧЕН

Азнакай шәһәрендә үзенең матур-төзек йорт-ихатасында машинасын караганда очраштык Әдип абый Мотыйгуллин белән. Автобусларда гомере буе пассажирлар йөрткән. Күптән түгел генә сиксән яшьлек юбилеен үзе эшләгән пассажир автотранспорт предприятиесе ветераннары, туган-тумачалары белән бик истәлекле итеп, чын бәйрәм төсендә үткәрделәр.

«Әле менә хәзер дә барлык таныклыкларымның срогы озайтылган, беренче класслылар, хет шушы минутта утырып чыгып кит автобус хезмәтенә», – дип әйтүендә дә аның үз һөнәренә чын күңелдән бирелгәнлеге күренеп, сокландырып тора. Күңелендә исә кайчакта шаулы яшьлеге яңарып куя. Туган авылы Кызыл Йолдызда тимерче әтисе янында бик кирәкле һөнәргә өйрәнеп үсә, тырышлыгын күреп, «Уразман» колхозы рәисе Нуретдин Хәйретдинов аны тракторчылар әзерләү курсына укырга җибәрә. Язгы чәчү башланганда кайтып та төшә ул. «КДП» тракторына утырып, бөртекләрне уңдырышлы туган туфрагына сала. Иген өлгерүгә, комбайнга утырталар үзен. Аннары хәрби комиссариат Әлмәттә шоферлар курсында укыта. Армия сафларында хезмәт итеп кайтуга, Азнакай пассажир автотранспорт предприятиесенә урнаша. «ЛАЗ»лар белән пассажирлар йөртеп, нинди генә авыл-шәһәрләрне урамый Әдип. Үз куллары белән йорт төзи башлагач, нефтьчеләрдә вахта машиналарын да йөртә. Кайда гына булмасын, беренче классны шофер тырышлыгы белән аерылып тора, ярышта җиңүче билгеләренә, «Хезмәт ветераны» исеменә лаек була. Хезмәттәшләре аны ветераннар советына, автоколоннаның цех комитеты рәисе итеп сайлыйлар. Ялларны күңелле үткәрү, тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуда башлап йөри ул. Шоферлар бригадиры буларак та хезмәт дисциплинасы үтәлешен контрольдә тота. Аның, 1980 елда Мәскәүдә үткән XXII Олимпия уеннарында хезмәт күрсәтүдә катнашып, РСФСР транспорт министрының үз кулыннан Мактау хаты белән бүләкләнүе дә данлы сәхифә бит! Авариясез эшләгән өчен күкрәк билгесе, район хакимияте, предприятиенең мактау грамоталарына ия. Элемтә хезмәтендә үзе кебек абруй казанган хатыны Зәлифә белән кыз һәм уллар үстереп, хәзер дүрт оныкларын тәрбиялиләр. Әдип абый урам комитеты рәисе буларак та, бик кирәкле су линиясе үткәрүдә тырышып йөри. «Бу изге хезмәт өчен депутатыбыз Рөстәм Мөхәммәдиев, район башлыгы Марсель Шәйдуллинга бик рәхмәтлебез, – ди ул. – Гомумән, бистәбез көннән-көн төзекләнә, ямьләнә, заманча шартлар тудырыла».

Бер дә буш вакыты юк аның. Әле менә умарталарын бик бөртекләп карап, кышкы саклауга куйган. Үзе дә шул бал кортлары кебек, тыз-быз чабып, эшеннән-шөгыленнән ямь табып яши ул.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай

БҮЛӘК

Биектау районы Торнаяз авылында рәссам-график, Бөек Ватан сугышы ветераны Хәйдәр Сайбаталовның 100 еллыгы уңаеннан ул яшәгән йортта музей ачылды. 42 ел иңне иңгә куеп яшәгән тормыш иптәше Ифира ханым тырышлыгы белән оешкан мондый бүләк.

Шәхси әйберләре, документлары, портретлары беренче катта урнаштырылган. Икенче катта карандаш белән ясаган рәсемнәре урын алган. Монда илебез тарихын, утны-суны кичкән еллар чагылышын күрергә була.

Рәссам Хәйдәр Гозаир улы 1923 елның 3 ноябрендә Кустанай шәһәрендә туа. Балачактан рәсем сәнгатенә сәләтле була ул. Газета чыгарып, мәктәп укучылары арасында мәгърифәт таратканы өчен, укытучысы аңа өч кабартма бирә. Бик ашыйсы килсә дә, авыру әнисенә алып кайта аларны бала. Кулыннан карандаш белән кәгазьне төшерми. Тик Свердловск театр институтындагы укуын дәһшәтле сугыш өзә. Ленинград фронтында пулеметчы егет каты яралана. Күп орден-медальләр белән бүләкләнә.

1954 елда Мәскәү полиграфия институтын тәмамлый, рәссам-график булып эшли. 1963 елдан Финляндиядә портретлар сериясен тудыра. Шуннан соң күп еллар Ленинград Югары сәнгать-сәнәгать институтында студентларга белем бирә, архитектура факультеты деканы вазыйфасын алып бара.

Рәссамның шәхси күргәзмәсе Россиянең төрле шәһәрләрендә һәм чит илләрдә оештырыла. Аның өч меңнән артык рәсем-портреты бар. Хезмәтләре император Петр I исемендәге үзәк хәрби-диңгез музеенда да саклана. Йөздән артык иҗат эшен Татарстан Сәнгать музеена тапшырган.

Беренче космонавт Юрий Гагаринның әнисе Анна Тимофеевна портреты җанлы сыман: аның зәңгәрсу күзләрендә миһербанлык мөлдерәп тора. Язучы Лев Гумилев, биюче Рудольф Нуриев портретлары да искиткеч уңышлы: характерларын ачып бирә алган ул.

– Кызыгыз булса, биюгә бирегез, дип киңәш бирде Рудик, – ди Ифира ханым.

Сүзенә колак салалар: 1961 елны туган кызларына Ирвена исеме кушып, балетка бирәләр. Хәләле Ифира ханымны да яратып, күңел җылысын кушып сурәтли рәссам. Музейда «Хатынымның 100 портреты» альбомын кулга тоткач, күңел мөлдерәмә тула: никадәрле ярату чагылган монда!

– Хәйдәремнең теләге халкыбызның абруен бөтендөнья күләмендә үстерү иде. Ул һәр кешенең үзенә генә хас булган сыйфатларын таба белде, – ди Ифира ханым үзе дә.

Педагог, тарих фәннәре кандидаты Әлфия Хәкимова рәссамның тормышы турында сөйләде.

Экспонатлар арасында якташым – Чуашстанның Козловка районы Кармыш авылында туган Татарстанның халык җырчысы Мөнирә Булатова 1949 елның 9 ноябрендә бүләк иткән фото күңелгә җылылык өстәде.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан

Фәнис энем маҗаралары

Чапшар сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, мин Казанга укырга киттем. Бервакыт Казаннан авылга ялга кайтып барганда, ферма янына җиткәч, берәү миңа әйтә (хәзер кем икәнен хәтерләмим инде): «Ә син беләсеңме, Фәнис энең әнә кызлар озатып йөри, сине уздырды бит!» – ди. Миңа ул вакытта – 15–16 яшь, ә Фәнискә 13–14 яшьләр тирәсе булгандыр. Кызлар озату турында башыма да кереп карамаган чак әле. Ә энем бик чая иде. Булгандыр, бер дә шикләнмим.

Алар авылда сыйныфташы Радис Габделхаков белән бик талантлы җырчылар, оста гармунчылар иде. Ел саен диярлек Балтачка җыр бәйгесенә барып, беренче урынны алып кайттылар. Җыр дәресен алып барган укытучыбыз, Пүскән авылыннан Борһанов Сәлим абый: «Радис белән Фәнис җыр буенча бөтен классыгызны тотып тора», – дип әйтә иде.

Бер елны колхоз рәисе Сәйдәш абый кырдан безнең казларны тотып алып, атлар конюшнясына ябып куя. Төнлә Фәнис дусты Фәндәс белән өй нигезе астыннан казып кереп, казларны коткара. Икенче көнне килеп карасалар, казлар юк. Бөтен кеше аптырап кала.

Алардан хәтта 4–5 яшькә олырак егетләр дә шүрләделәр. Авылга кызлар янына килеп, кукраеп йөрсәләр, хәзер акылга утырталар иде. Шуңа күрә күрше авыл егетләре дә алар белән дус булырга тырыштылар. Авыл егетләрен уч төбендә тотучы күршебез Зөфәр дә аларга: «Егетләр булды инде, нигә шул Курмала, Норма егетләренә тиясез, безнең бит алар белән яшисе, эшлисе бар!» – дип, аларны сүгеп тә ата иде.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.
Казан

ЮГАЛТУ САГЫШЫ

Исән булса, быел гыйнвар аенда якташыбыз, халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевкә 77 яшь тулган булыр иде. Әдипнең туган көнендә Түбән Каманың Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханәсендә аны зурлап искә алдылар.

«Бу дөньяның мин бер кисәкчеге, Мин – кечкенә генә материк. Таулар да бар миндә, упкыннар да, Батырлык бар миндә, матурлык...» Экраннан Разил абый үзенең «Кеше» шигырен укый. Менә укып бетерер дә: «Газиз якташларым, бүгенге кичәгә килә алмадым инде. Ләкин күңелем, уйларым белән мин гел сезнең янда. Бу шигыремне сагынычлы кайнар сәламем дип кабул итегез», – дияр кебек тоела.

Әйе, аның турында үткән заманда сөйләргә авыр. Арабыздан мәңгелеккә киткәненә әле һаман ышанып булмый. Чара башында ук мөлдерәмә тулган күңел, Түбән Кама үзәкләштерелгән китапханәләр берләшмәсе директоры Гөлназ Арсланова, кулына микрофон алып, шагыйрь сүзләренә язылган «Кышкы учак» җырын җырлый башлагач, тәмам ташып түгелде...

Кичә матур хатирәләргә, җылы сүзләргә бай булды. Әдипнең бертуган энесе Рәмзил Вәлиев абыйсына бәйле истәлекләрен уртаклашты. «Без гаиләдә сигез бала үстек. Разил абый безнең өчен һәрчак үрнәк булды. Аңардан калган бишмәт мине кышкы зәмһәрир салкыннардан сакласа, аның күңел җылысы тормыш киртәләрен җиңәргә ярдәм итте. Әткәй урынына калган кадерле кешем иде. Бик юксынам үзен. Туган җанлы, ярдәмчел булуы белән аерылып торды, кешеләрдә гел матурлык кына эзләде. Туган ягын сагынып яшәде. Авылга кайткач, иртәнге дүрттә торып, урамнарны, болыннарны урап кайта иде. Әнә шулай җанына тынычлык, илһам ала, үткәннәре, яшьлеге белән очраша сыман тоела иде миңа», – диде Рәмзил әфәнде.

Түбән Кама муниципаль районы башкара комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Илдар Рамазанов Разил Вәлиевне татар халкының горурлыгы дип атады һәм әдипнең туган ягында аның исемен мәңгеләштерү буенча зур эшләр башкарылырга тиешлеге турында әйтте.

Чарага Казан һәм Чаллы шәһәрләреннән мәртәбәле кунаклар – шагыйрьнең иҗатташ дуслары да килгән иде. Халык шагыйре Рәдиф Гаташ: «Разилнең туган ягына кайткач, аны югалту сагышы тагын да көчәйде. Алыштырмас кешеләр юк, дисәләр дә, Разил безнең бик күпләребез өчен алыштыргысыз дус, туган, бәлки, бу якларның йөз елга бер тапкыр туа торган улы иде», – дип сөйләде.

Зиннур Мансуров Разил Вәлиевне татар әдәбиятының алтын баганасы дип атады. «Татар язучылары элек-электән беркайчан да әдәби иҗат белән генә чикләнмәгән. Разилнең халкыбыз өчен башкарган эшләрен күздән кичерсәң, аның татар әдибе статусын берничә башка күтәрүенә инанасың», – диде язучы.

Марсель Галиев шагыйрьнең туган авылы Ташлыкта иске мәчетне яңартып, манарасына ай кую мәшәкатьләре белән йөргән чакларны искә алды: «Партия заманы иде ул. Шуңа да, булдыра алырмы икән, дип шикләндек. Булдырды! Күрше-тирә авыл халкы да әлеге зур вакыйганы карарга килгән. Нинди көчле рухлы безнең халык, дип, шаккатып, сокланып сөйләгәнен хәтерлим. Ул шушы рухны гомере буе тоеп яшәде, шул рух аның үзен дә яшәтте, зур эшләргә илһамландырды».

Факил Сафинның да язучыга бәйле хатирәләре күп иде. Ул Разил Вәлиевнең Язучылар берләшмәсенең Чаллы бүлеге белән җитәкчелек иткән елларын хәтердә яңартты. Рәшит Ваһапов исемендәге татар мәдәнияте фонды җитәкчесе Рифат Фәттахов әдипнең, Кайгыртучылар советы рәисе буларак, фонд эшен үстерүгә күп көч куюына басым ясады.

Чарада Разил абыйның авылдашы, якын дусты, сабакташы Алмаз Хәмзин дә катнашты. Алмаз абый дигәч, Разил Вәлиевнең бер әңгәмәсендә: «Мәктәптә укыганда, мин җырлап йөрдем, ә Алмаз шигырьләр яза иде. Аннан соң урыннарны алмаштык һәм дөрес эшләгәнбез», – дип көлеп әйткән сүзләре искә төште. Күренеп тора: Алмаз абый да бик юксына Разил дустын.

Шагыйрь, драматург, дәүләт эшлеклесе, милләтпәрвәр, мәгърифәтче, тәрҗемәче, күпсанлы мактаулы исемнәр иясе, чын көрәшче, оста тәрбияче, менә дигән психолог, чын дипломат... Әйе, кичәдә катнашкан һәркем Разил Вәлиевне үзенчә ачты. Билгеле инде, аның 30 елдан артык гомеренең китапханәгә бәйле булуы, үзе җитәкләгән Милли китапханәне Татарстан, татар халкының милли символы дәрәҗәсенә күтәрүе турында әйтми китү дә мөмкин түгел иде. Чыннан да, татар китабына җылы урын тапкан, китапханәләр эшенә яңа сулыш өргән шәхес тә иде ул. Шуңа күрә шагыйрьне искә алу кичәсенең нәкъ менә китапханәдә үтүе дә табигый сыман.

...Кичә тәмам. Кайтыр юлга чыгам. Ә колакта һаман таныш көй яңгырап тора: «Ява карлар, яңа карлар, Яңа елның кары ява...» Без генә түгел, яңа елның бөтерелеп яуган ак кары да, туган авылың Ташлыкның син тәгәрәп үскән чирәмле урамнары, печән чапкан хуш исле болыннары, кулларың җылысы, күз нурларың саклаган китапларың, алай гынамы – бар җиһан сагыныр сине, Разил абый!..

Айгөл ГӘРӘЕВА.
Түбән Кама

Казлар

Аулаш елгасы янындагы болында, көзгә таба симереп, бакча кабагыдай шыплап торган аклы-күкле каз көтүләре, авыр тәпиләрен алпан-тилпән күчереп, саргая төшкән үлән чемләп йөри. Аратирә муеннарын сузып, куркыныч-мазар юкмы дигәндәй, күзәткәләп тә алалар. Берәр гауга чыгып, ата казлар сугыша башласа, үз телендә пыр туздырып ачуланып, га-га килеп, кайсындыр каһәрли-каһәрли, төрлесе-төрле якка очкан чакта болын өсте яу кырыдай була. Безнең оч казлары бу. Суда чумып, тукланып, аралашып үткән көн азагында, болын битен кауырыйлардан, канатлардан акка манып, үз юлларын белеп, өйләренә кайтып китә казлар. Ул казларның кайтып киткәнен көтеп кенә торабыз да каурый-канат җыярга уңайлы кәрҗин-фәлән тотып, су буена төшәбез. Мул, йомшак булсын дисәң, олы ястыкка каз мамыгы бихисап кирәк бит. Кич утырып, ул канатларны сөенә-сөенә сыдыра идек. Үзебезгә шөгыль табып кына тора идек шул без.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА.
Казан

ҮЗЕБЕЗНЕҢ БАТЫРЛАР

Илдар Мөхәммәтҗанов

<Ахыры. Башы 1 нче биттә

Сөенечне икегә тапкырладылар

Бәйге келәмендә бу мөнәсәбәтнең нәтиҗәсен күрдек. Очраклы җиңү бер мәртәбә булырга мөмкин. Калганы – еллар буе башкарылган хезмәт җимеше. Алга китеп булса да шуны әйтик: быелгы бәйгедә 8 егет узган елгы батырлыгын кабатлый алды. Иң җиңел һәм иң авыр категорияләрдә чыгыш ясаган көрәшчеләр янә җиңүче исемен яулады. Ә сөенечләре тагын да зуррак булды. Ник дигәндә, Муса Җәлил турнирында батыр калган егетләргә быел 100әр мең сум күләмендә бүләк тапшырдылар. Икенче урын алучылар – 70, өченчедә калучылар 50шәр мең сумга ия булды.

Былтыргы уңышын кабатлаучыларның беренчесе – Лаештан Алексей Абрамов. 60 килога кадәрге категориядә чыгыш ясаучы егет узган елгы финалда үзе белән бер командада чыгыш ясаган Илфат Миңнегалиевтан өстен чыкты. Бу юлы исә Әлмәттән 20 яшьлек Рубин Рәҗәбовны отты. Әлеге көндәшлек озак елларга сузылырга мөмкин әле. Илнар Закировның да дусты Алексейдан калышасы килмәде. 65 килолы егетләр арасында узган хәлиткеч алышта Чистай командасы вәкиле әле оешып кына килүче «Зилант» клубыннан Алмаз Миңнехуҗинны чистага салды һәм газетабыз бәйгесендә дүртенче җиңүен яулады.

Алабугадан Ислам хаҗи Фәлаховның хәзер өч җиңүе бар. Лаеш командасыннан Илназ Рамазанов белән озак тартышты алар. Илназ узган ел 75 килолы егетләр арасында икенче булса, быел 70ләр ярышында батыр асты калды. Илназның тренеры Динар Кәримуллин исә, 75ләр арасында икенче ел рәттән батыр калып, җиңүләр санын дүрткә җиткерде. Финалда ул Чистайдан Булат Гадершиннан өстен чыкты.

Абый киткәч

Узган ел 80 килолы егетләр арасында Теләчедән Эмиль Мавлин җиңү яулаган иде. Быел Әлмәт өчен бил алышкан Рафаэль Кәлимуллинга тиңнәр булмады. Муса Җәлил бәйгесендә беренче мәртәбә батыр калган егеткә Кәлимуллиннарның абруен саклау өчен икеләтә тырышырга туры киләчәк. Авырлыгы 85 килодан артмаган көрәшчеләр арасында да яңа батыр. Былтыр Рафаэльнең абыйсы Ренас сигезенче җиңүенә ирешкән иде. «Ренас тәнәфескә чыкмый», – дип язганбыз узган ел. Тәнәфес сорап килми икән. Быел әлеге категориядә иң көчле егет булып Лаештан 21 яшьлек Рүзәл Тимергалиев танылды. Кукмарада туып-үскән егет хәлиткеч очрашуда үзеннән 15 яшькә өлкәнрәк Фаяз Зариповны отты. Фаяз – Арча егете, ә хәзер «Зилант» өчен бил алыша. Әмма барыбер Илшат абыйсы Идиатовтан ерак китми.

Чаллыдан Азат Габдрәшитов белән Рөстәм Сәлахов узган ел 85 килолы егетләр ярышында икенче һәм өченче булганнар иде. Берсе – Актаныштан, икенчесе – Зәйдән. Ел дәвамында икесе дә 5 килога авырайганнар. Бу юлы 90нар финалында очраштылар. Рөстәм бил алышканда абыйсы Радик бик борчылса да, Азат өстен чыкты.

Татарның көрәш дөньясында иң танылган егетләрнең берсе Булат Мусин быел 30 яшен тутыра. Яңа Чишмә егетенең осталыгы беркайчан да шик уятмады. Ходай биргән сәләте янына җитдилек тә өстәлгәч, Булат бер башка күтәрелеп киткәндәй булды. Хәлиткеч ярышларда ул, башта Илнар Галимовны, аннары Егор Такарлыковны чистага салып, үзенең өстенлеген тагын бер кат раслады. Хәзер Мусинның Муса Җәлил бәйгеләрендә алты җиңүе бар. 115 килолы егетләр ярышын икенче ел рәттән откан Раил Нургалиевка, легендар батыр Айрат Гыйлаев белән янәшә басар өчен, нибары бер адым ясыйсы калды. Газетабыз турнирын Раил – 11, Айрат 12 тапкыр отты. Шикләнмибез, Нургалиев тарихка кереп калу өчен барысын да эшләячәк.

Авырлар җиңел көрәшә

Иң авыр категорияләрдә соңгы еллардагы ярышларны күреп, күңел сөенә. Сер түгел, дәүләр арасындагы очрашулар бил алышудан бигрәк этеш-төртешкә әверелә иде. Яшь егетләр барысын да үзгәртте. Зәй егете Радик Сәлаховка авырлыгы 130 килодан артмаган көрәшчеләр арасында тиңнәр юк. Моңарчы Әлмәт һәм Лаеш өчен бил алышкан Радик җиңеп чыккач, аны Чаллы егетләре күккә чөйде. Келәмнән чыккач, көндәшләр көрәштәшкә әверелә. Хәзер Сәлаховның биш җиңүе бар. Энесе Рөстәмнең батыр каласына да нык өметләнде ул. Бераз сабыр итәргә туры киләчәк. Алар белән Чаллы келәмендә бергә шөгыльләнүче Ранис Гыйлаҗетдинов иң авыр категориядә җиңү белән генә чикләнмәде һәм Ильяс Галимов исемен йөртүче бүләккә дә лаек булды. «Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Көрәш федерациясенең уртак бүләге финалда иң яхшы алым күрсәткән егетләргә инде дүртенче ел рәттән тапшырыла. Ранисның ничек бил алышканын күреп торса, Ильяс абыйсы да сөенер иде. Келәмдә Гыйлаҗетдиновны аркасына салырлык бер генә кеше бар: тренеры Илнур Хәйбуллин. Шәкерте батыр калгач, остазның аны күтәреп, чистага салуы көрәш ярышларының матур гадәтенә әверелде.

Командалар ярышында өченче урында – Әлмәт егетләре. Былтыр өченче булган Теләче быел икенчегә күтәрелде. Турнирны икенче ел рәттән Лаеш егетләре отты. Район башкарма комитеты җитәкчесе Азат Нурмөхәммәтов якташларын зур бәйгеләргә фәнни дәрәҗәдә төгәллек белән әзерли. Барысы да үлчәнгән һәм төгәл исәпләнгән. Икенче урынны алган Теләчедә дә көрәшкә шундый мөнәсәбәт. Район башлыгы урынбасары Айрат Фәтхуллин баштан ахырга кадәр үзе күзәтеп тора. Ялгышырга урын юк. Ә мәйданга шушы ике район егете чыкса, келәм читендә Теләче Сабан туе башлана! Хәер, кемнең кайдан булуы мөһим түгел. Барысы да – үзебезнең батырлар!

Илнар ХӨСНУЛЛИН,
Лилия ГЫЙМАЗОВА

БЫЕЛГЫ БӘЙГЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ

60 кило
I урын – Алексей Абрамов (Лаеш)
II урын – Рубин Рәҗәбов (Әлмәт)
III урын – Ильяс Йосыпов (Балтач), Ленар Әүхәдиев (Балтач)

65 кило
I урын – Илнар Закиров (Чистай)
II урын – Алмаз Миңнехуҗин («Зилант»)
III урын – Рәсим Хаҗиев (Әлмәт), Райнур Фәйзрахманов («Зилант»)

70 кило
I урын – Ислам Фәлахов (Алабуга)
II урын – Илназ Рамазанов (Лаеш)
III урын – Илнар Муллахмәтов (Балтач),
Илсаф Ишмөхәммәтов (Лаеш)

75 кило
I урын – Динар Кәримуллин (Лаеш)
II урын – Булат Гадершин (Чистай)
III урын – Мөнир Галләмов (Теләче), Камил Хаҗиев (Әтнә)

80 кило
I урын – Рафаэль Кәлимуллин (Әлмәт)
II урын – Айнур Нургалиев (Мамадыш)
III урын – Инсаф Кәримуллин (Арча), Рамиз Исрафилов (Кукмара)

85 кило
I урын – Рүзәл Тимергалиев (Лаеш)
II урын – Фаяз Зарипов («Зилант»)
III урын – Инсаф Мөбарәкшин (Арча), Илгизәр Галимуллин (Балтач)

90 кило
I урын – Азат Габдрәшитов (Чаллы)
II урын – Рөстәм Сәлахов (Чаллы)
III урын – Рамил Мөхәммәтов (Теләче), Ранис Галимуллин (Лаеш)

100 кило
I урын – Булат Мусин (Чистай)
II урын – Егор Такарлыков (Чаллы)
III урын – Айгиз Зәйнетдинов (Теләче), Илнар Галимов (Чаллы)

115 кило
I урын – Раил Нургалиев (Теләче)
II урын – Айнур Сыртаев (Чистай)
III урын – Дилүс Закиров (Саба), Рифат Ахунҗанов (Саба)

130 кило
I урын – Радик Сәлахов (Лаеш)
II урын – Раил Мараков (Теләче)
III урын – Ирек Шаяхмәтов (Әлмәт), Ринат Дәүләтшин (Кукмара)

130+ кило
I урын – Ранис Гыйлаҗетдинов (Чаллы)
II урын – Муса Галләмов (Лаеш)
III урын – Валерий Леонтьев (Саба), Константин Морозов (Түбән Кама)

Командалар беренчелеге

1. Лаеш	6. Чистай
2. Теләче	7. Балтач
3. Әлмәт	8. Арча
4. «Зилант»	9. Кукмара
5. Чаллы	10. Саба

Гадәттәгечә Муса Җәлил бәйгесендә узган елның иң яхшы көрәшчеләрен, тренерларын, хөкемдарларын бүләкләделәр.

Иң яхшы көрәшчеләр: Радик Сәлахов, Динар Кәримуллин, Раил Сәлахетдинов, Ранис Гыйлаҗетдинов.

Яшьләр белән эшләүче иң яхшы тренерлар: Рүзил Ганиев, Илгиз Шәмсевәлиев, Динар Кәримуллин.

Өлкәннәр белән эшләүче иң яхшы тренерлар: Илнур Хәйбуллин, Җәүдәт Хөсәенов, Динар Кәримуллин.

Иң яхшы командалар: Әлмәт, Чаллы, Арча, Кукмара, Балтач.

«Ел ачышы» булган командалар: Чистай, Лаеш, Азнакай.

Алексей АБРАМОВ:



– Күптән түгел Татарстан чемпионатында җиңелдем, әзерлегем шуның чаклы гына иде. Бу юлы реванш алдым дисәм дә була, бик каты әзерләндек. Үзем өчен иң әһәмиятле турнирда икенче тапкыр җиңү – зур нәтиҗә инде ул. Монда ел саен иң көчлеләр җыела.

Илнар ЗАКИРОВ:

– Беренче җиңү белән чагыштырып булмый, билгеле. Беренче җиңү – иң шәбе, иң истә кала торганы, иң кадерлесе. Икенче һәм аннан соңгы җиңүләр бераз тынычландыра, яхшы формада булуыңны раслый. Җиңү лидерлыкны саклауга караганда җиңелрәк.

Ислам ФӘЛАХОВ:

– Ел саен үземә: «Бу юлы да сынатмаска!» – дип, җиңү бурычы куям. Бу юлы да бурыч үтәлде, мин канәгать. Яшермим, финалда бил алышу җиңел булмады. Илназ белән (Рамазанов. – **Авт.**) бер-беребезне яхшы беләбез, ахыргача киеренке көрәш булды.

Динар КӘРИМУЛЛИН:

– Бу җиңү – тырышлык нәтиҗәсе. Мин бар көчемне, бөтен вакытымны көрәшкә бирәм. Кичә генә «Иң яхшы көрәшче» исемен алып, бүген үземдә шөгыльләнүче егетләр алдында көрәшү икеләтә җаваплылык булды. Мин алар өчен чын мәгънәсендә үрнәк булырга тиеш бит.

Рафаэль КӘЛИМУЛЛИН:

– Иң беренче һәм иң кадерле җиңүем. Ике көне дә бик киеренке булды. Шуңа да хәзерге вакытта хис-кичерешләремне әйтеп аңлатып булмый. Дөресен генә әйткәндә, миңа җиңүләремнең саны да мөһим түгел. Чын мәгънәсендә халык чемпионы буласым килә.

Рүзәл ТИМЕРГАЛИЕВ:

– Турнирга кадәр дүрт килога ябыгырга туры килде, моңарчы 90 килода көрәшә идем. Бу категориядә моңа кадәр Фаяз (Зарипов. – **Авт.**) җиңеп килде. Аның белән беренче тапкыр көрәштем. Финалдагы алышта аннан өстен булу – минем өчен икеләтә җиңү.

Азат ГАБДРӘШИТОВ:

– Башка елларны призлы урыннарда гына кала идем, күптән көтелгән җиңү бу. 10 еллап тырышырга туры килде. Соңгы алышта командадашым белән көрәштек. Аның алымнарын белгәч, җиңел булды. Ләкин аны кимсетәсе дә килми. Хәер, көрәштә дус-туганлык онытыла.

Булат МУСИН:

– Күреп торасыз, көрәш бик киеренке булды. Егетләр яхшы әзерләнгән. Кайсыдыр алыш җиңелрәк, кайсыдыр авыррак булды, дип әйтеп булмый. Һәр көрәшче үзенчәлекле, һәркайсына аерым алым кирәк. Ләкин, шөкер, бүген бәхет миңа елмайды. Бу – инде алтынчы җиңүем.

Раил НУРГАЛИЕВ:

– Аллаһы Тәгаләгә, әниемә, гаиләмә һәм минем өчен җан аткан һәркемгә рәхмәтле мин бүген. Бу турнирның дәрәҗәсе елдан-ел арта. Шулай дәвам итсен! Безнең өчен бик әһәмиятле бәйге ул. Быел аның ачылыш тантанасын барыбыз да дулкынланып карадык, оештыручыларга бик зур рәхмәт!

Радик СӘЛАХОВ:

– Бу җиңүемне дә, беренче чиратта, әтиемә багышлыйм. Әлегәниләр кичергәнемне әйтеп аңлату кыен. Гадәттә, җиңеп кайтып, берәр атнадан соң гына аңыша башлыйм. Турнирга кадәр имгәнгән идем, шуңа да бу юлы авыррак булды. Ләкин җиңәргә насыйп булган икән.

Ранис ГЫЙЛАҖЕТДИНОВ:

– Бу турнир – күңел бәйрәме. Монысы – өченче җиңүем. Соңгы алышта Муса Галләмов белән көрәштек. Бер-беребезне шактыйдан беләбез, икебезнең дә тәҗрибә бар, шуңа финал аеруча авыр, киеренке барды. Бик каты әзерләндек, шөкер, нәтиҗәсе дә булды.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының уздак каталогына кертелгән.
Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 213

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+